ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ
# 1612–2022

**Библиографик күрсәткеч**

Казан
2022

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени Г. ИБРАГИМОВА

# ТАТАРСКИЙ ФОЛЬКЛОР
# 1612–2022

**Библиографический указатель**

Казань
2022

**УДК 398(01)**
**ББК 91.9:82.3(2=632.3)**
**Т 23**

*Печатается по решению Ученого совета*
*Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова*
*Академии наук Республики Татарстан*

**Редколлегия:**
К. М. Миннуллин, И. И. Ямалтдинов,
И. Г. Закирова, Р. Ф. Сафиуллина

**Составители:**
*А. Г. Каримуллин, Д. Р. Галиуллина*

**Рецензенты:**
*доктор филологических наук Л. Х. Давлетшина,*
*кандидат педагогических наук Р. М. Барейчева*

**Т 23** **Татарский фольклор:** 1612–2022: Библиографический указатель = Татар фольклоры: 1612–2022: Библиографик күрсәткеч. – Казань, 2022. – 480 с.
ISBN 978-5-93091-422-1

В библиографическом указателе отражены научные исследования, сборники фольклорных материалов и иные работы по татарскому фольклору, вышедшие в период с 1612 по 2022 год. Сборник адресован ученым, аспирантам, студентам гуманитарных специальностей, и всем тем, кто интересуется вопросами татарского фольклора.

УДК 398(01)
ББК 91.9:82.3(2=632.3)

**ISBN 978-5-93091-422-1**

© Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2022

## ВВЕДЕНИЕ[1]

### Из истории собирания и изучения татарского фольклора

Некоторые образцы устного народного творчества тюркских народов древности, в том числе и поволжских тюрков, еще тысячу лет тому назад начали обретать свое воплощение на бумаге. К примеру, по записям арабского путешественника и писателя Ибн Фадлана, посетившего Булгарское ханство в 992 году, можно ознакомиться со множеством обрядов и верований, легенд и преданий булгар – предков казанских татар. В словаре известного тюрколога XI столетия Махмута Кашгари «Девану лугатит-тюрк» (1072–1074) можно встретить много фольклорных произведений. «Я эту книгу… щедро украсил рифмованной прозой, пословицами, поэзией, одами, прославляющими подвиги наших героев, и рассказами», – пишет М. Кашгари[2]. Не вдаваясь в подробности данных произведений, отметим следующее: в книге есть и песня об Идели, и дошедшие до наших дней предания татарского народа о сыне пророка Ноя Иафете, а также о его сыновьях Гази, Туреке, Алыпе. Из 307 опубликованных в этом словаре пословиц и поговорок около 120 входят в действующий репертуар татарского фольклора. Зачастую древняя версия и современная почти слово в слово повторяют друг друга: Арслан карыса, сычган өтин күдәзүр – Арыслан картайса, тычкан өнен күзәтер (Старого льва и мыши не боятся); Бар бакыр, йок алтун – Бар бакыр, юк алтын (Где медь, золота нет); Бөринең ортак, кузгуннуң йыгач

---

[1] За основу взята вступительная статья к книге «Татарский фольклор. Библиографический указатель» (1993), написанная А. Каримуллиным и Х. Махмутовым, которая отредактирована и дополнена с учетом современных требований. Ввиду того, что в указателе 1993 года отражен период с 1612 по 1981 гг., во второй части статьи освещается развитие фольклористики за последние сорок лет.

[2] *Кошгарий Махмуд.* Туркий сүзлар девони (Девону луготит турк). – I т. – Тошкент, 1960. С. 44–45.

башында – Бүренеке уртак, козгынныкы агач башында (Добыча волка – общая, а воронья – на дереве); Ике кочңар башы бир ашычта бешмәс – Ике кучкар башы бер табакка сыймас (Две бараньи головы в один котел не поместятся); Көккә сагурса, йүзкә түшүр – Күккә төкерсә, битеңә төшәр (Если плюнешь в небо, на тебя же и попадет) и др.

Известно, что в XIII–XIV веках в Поволжье, а также в некоторых других регионах проживания тюрков, в особенности, у кипчаков, оказавших большое влияние на формирование казанских татар как самостоятельного народа, начали создаваться словари. Больше десятка подобных изданий сохранились и ныне. Одну из этих книг, а именно «Кодекс Куманикус», составленный в 1303 году, есть все основания считать отправной точкой изучения татарского фольклора. Из произведений фольклора здесь опубликованы 46 загадок. По тематике, по поэтической конструкции, по речевым оттенкам они очень близки к современным загадкам, а иногда демонстрируют даже текстуальную схожесть. Имеющиеся различия проявляются лишь в использовании архаичных слов.

Образцы фольклора можно встретить в произведениях древней татарской литературы: «Кыссаи Йосыф» (XIII век) Кул Гали, «Нахдж ал-фарадис» (1358) Махмуда бин Гали, «Хосров и Ширин» Кутба (XIV век), «Гулистан бит-тюрки» Сейф Сараи (XIVвек), Хисама Кятиба «Джумджума султан» (XIV век) и во многих других текстах. Их можно отыскать и в многочисленных древних татарских рукописях, хранящихся в библиотеках Казани, Ленинграда и других городов.

Первое печатное издание, имеющее отношение к татарскому фольклору – грамматика и словарь кыпчакского языка, опубликованные Иеронимом Мегизером в 1612 году в Лейпциге. В этой книге в качестве развивающих примеров или упражнений для чтения увидело свет больше 220 пословиц и поговорок. Аналогичную картину можно наблюдать и в грамматике Д. Франческо-Марио Магджио (Рим, 1643). Народные афоризмы, легенды-предания сохранились также в трудах европейских историков и путешественников о тюрках и татарах, написанных в XVI–XVIII вв.

В России произведения татарского фольклора начали собирать в XVIII веке. После создания в Петербурге в 1725 году Академии наук под ее патронажем организуются экспедиции по изучению истории и этнографии проживающих в империи народов, одновременно с этим большое внимание стали уделять и фольклору. В трудах Г. Ф. Миллера, П. С. Палласа, И. И. Лепехина, Н. П. Рычкова, М. Д. Чулкова наряду с фольклорными произведениями других народов занимают место сведения о песнях и плясках, играх и праздниках, легендах и преданиях татар. Однако данную работу нельзя назвать полноценным сбором материалов по татарскому фольклору, так как это были всего лишь иллюстративные образцы для описания этнографии исследуемых народов.

Будет справедливым назвать одним из первооснователей собирания татарского фольклора Ивана Добровольского. Открыв в Астрахани в 1816 году литографию, он выпускает «Азиатский журнал». На страницах журнала публикуются тексты и ноты тюркских и в особенности татарских песен.

В тридцатых годах XIX века стараниями И. Снегирева, В. Романовича, в середине пятидесятых годов – Н. Берга собираются и публикуются произведения татарского фольклора (песни, пословицы, поговорки).

Результатом учреждения и открытия в Казани университета явился значительный прогресс в изучении истории, литературы, языков, культур народов Востока и Поволжья. А открытие в 1878 году под сводами университета Общества археологии, истории и этнографии и выпуск «Известий» придало еще больший масштаб этому делу. Значительный вклад в сбор и изучение фольклора вносят ученые университета, члены научного общества К. Фукс, И. Готвальд, А. Артемьев, И. Н. Березин, В. В. Радлов, Н. Ф. Катанов и др.

Будет справедливым отметить, что значительным вкладом в изучение татарского народного творчества стала выпущенная в первой половине XIX века «Татарская хрестоматия» Мартиньяна Иванова, отпечатанная в 1842 году в типографии Казанского университета. Учителю татарского языка в Оренбургском кадетском корпусе Неплюева М. Иванову удалось

опубликовать в вышеупомянутом сборнике 128 пословиц, 70 песен, 34 загадки и 8 сказок.

Во второй половине минувшего столетия сбор произведений устного творчества татар продолжается не только в Казани, но и в Сибири, на Урале, в Астрахани, Пензе, Рязани, Саратове; материалы по данной теме регулярно публикуются на страницах «Известий», выпускаемых Российской Академией наук, губернскими отделениями географического общества, а также в губернских «Ведомостях».

Среди появившихся в этот период работ выделяются важностью и полнотой собранных материалов работы Р. Г. Игнатьева, Н. Кострова, И. Покровского, В. Витевского, С. Г. Рыбакова.

Особого внимания достойны и работы зарубежных тюркологов-фольклористов второй половины XIX–XX вв. Примером тому служат сборники Габора Балинта (Будапешт, 1875), Арминия Вамбери (Лейпциг, 1885), Хейкки Паасонена (Хельсинки, 1901) и др.

Открытие в Казани в 1800 году первой татарской типографии, появление татарских печатных изданий оказало благоприятное влияние на сбор и публикацию произведений татарского фольклора среди самих татар. «Кыссу Суйфульмулюка», превратившуюся в народную сказку, в 1807 году одновременно выпустили двумя отдельными изданиями, в 1829 году увидели свет «Кыссаи Йосыф», в 1845 истории Ходжы Насретдина, в 1848 году «Кысса Сулеймана», позже каждая из упомянутых книг переиздавалась почти ежегодно. В 1852 году выпускают «Русско-татарскую азбуку» Габдеша Вагапова. Позже и до самой революции выпускается учебник «Үзи-үзидән өйрәткеч» (Самоучитель). На его страницах публикуются татарские народные песни, мэзэки (народные шутки), сказки, пословицы, поговорки. В 1869 году Г. Вагапов выпускает первый сборник татарских народных песен под названием «Песни». Г. Махмутов, С. Кукляшев, М. Бикчурин и другие татарские ученые активно используют фольклор в своих научных трудах, посвященных татарскому языку.

Во второй половине XIX столетия видные татарские ученые Г. Фаизханов, М. Салихов, Т. Яхин, Г. Минеев, Ф. Халиди и мно-

гие другие внесли большой вклад в сбор, изучение и издание произведений татарского фольклора. С 1870–1880 годов начинают выходить десятки сборников кысса, анекдотов, хикаятов без указания собирателей и составителей. Усиливается внимание к переводам фольклорных произведений народов Востока на татарский язык. Публикуются «Тутыйнамэ», «Кэлилэ вэ Димнэ», полный цикл «Тысячи и одной ночи». Если в 1807–1870 годах фольклорных изданий выходило одно-два-три, то после 1880 года книги о татарском народном творчестве ежегодно переиздавались по нескольку раз, по нашим сведениям, в 1880 – 7, в 1881 – 7, в 1882 – 4, в 1883 – 12, в 1887 – 9, в 1888 – 10, в 1889 – 15, в 1896 – 24, в 1897 – 20. Их средний тираж составлял по 2400, 5000, 10 000 экземпляров.

В эти годы особенно глубокий след в изучении истории фольклора оставил видный ученый, педагог, энциклопедист Каюм Насыри. Татарский фольклорист Хамит Ярми отмечал, что деятельность Насыри развивалась по трем направлениям[1]. Во-первых, он непосредственно собирал фольклор, напрямую записывая его из уст народных исполнителей, бережно обрабатывал, объединял лучшие произведения народного творчества под одной обложкой и выпускал сборники. Во-вторых, важнейшей задачей для себя Каюм Насыри считал ознакомление других народов с историей, бытом, мировоззрением своего народа, немалых усилий потребовал от ученого перевод на русский язык самых ярких, характерных произведений татарского фольклора. В-третьих, просветитель-ученый подробно изучил наследие фольклора Востока и лучшие образцы из отобранных жемчужин перевел на татарский язык и выпустил отдельными книгами.[2]

Разумеется, первое направление шире и глубже, чем просто сбор и публикация фольклора. К. Насыри систематизировал процесс сбора и публикации произведений народного творчества, разделил их на жанры, написал определения каждого

[1] *Ярми Х.* Поэтическое творчество татарского народа. – Казан, 1967. – С. 30–31.

[2] *Бадиги Х.* Труды К. Насыри по сбору и учету народного литературного творчества // Сборник о Каюме Насыри. – Казань, 1922. – С. 104.

жанра, а к некоторым произведениям подготовил комментарии. По сравнению с работами предшественников и современников, труды К. Насыри, с одной стороны, отличаются объемом и качеством собранных материалов, наличием практически всех фольклорных жанров. С другой стороны, как наиболее важную особенность многогранной деятельности Каюма Насыри, отличившую его от предшественников, занимавшихся только сбором и публикацией фольклора, либо использовавших собранные материалы в лингвистических, историко-этнографических, хрестоматийных и учебных пособиях следует подчеркнуть, что он заложил основы изучения фольклора как самостоятельной науки. «Каюм Насыри, – пишет Хужа Бадиги, – выходец из среды казанских татар … считал отдельной наукой… изучение народных песен, баитов, частушек, мелодий… это он доказывал, кропотливо изучая всё, что видел или слышал из уст народа. Ученый вернул это богатство в народ, ни капли не расплескав»[1].

Иначе говоря, переход от этапа собирательства фольклора и его публикации к формированию его изучения как самостоятельной науки непосредственно связан с деятельностью К. Насыри.

В начале XX столетия особенно в итоге революции 1905–1907 годов быстрыми темпами стали расти публикации фольклора на татарском языке. Количество татарских типографий увеличилось, возникли десятки издательств. А издательства, пользуясь ажиотажным спросом на книги, печатали всё, что попадало на редакторские столы. Вот в таких условиях один за другим «пеклись» песенные сборники объемом в 16, 24, 32 страницы. Наряду с издательским хаосом стали появляться и ученые, планомерно собиравшие произведения народного творчества, используя научный подход. В первую очередь большой вклад в татарскую фольклористику внесли Ш. Рахматуллин, Ш. Хамидуллин, Г. Арсланов, Г. Рашиди, Ф. Туйкин, Г. Камал, Ф. Амирхан, Х. Бадиги, А. Белеш, Г. Рахим и др.

---

[1] *Бадиги Х.* Труды К. Насыри по сбору и учету народного литературного творчества // Сборник о Каюме Насыри. – Казань, 1922. – С. 104.

Великий татарский поэт Габдулла Тукай искренне интересовался жемчужинами народного творчества, собирал и подробно их изучал и издавал. Его вклад в пропаганду татарского фольклора также трудно переоценить. Г. Тукай, Г. Ибрагимов, продолжая заложенные К. Насыри традиции, отдают предпочтение научному подходу в изучении фольклора.

Рост спроса на фольклорные издания на татарском языке в 1907–1916 годах открыто демонстрирует нижеприведенная таблица[1]:

| Год | Число изданий | Издания, чьи тиражи известны, и суммарный тираж |
|---|---|---|
| 1907 | 20 | 18 – 90 000 экз. |
| 1908 | 21 | 19 – 125 800 экз. |
| 1909 | 34 | 30 – 234 400 экз. |
| 1910 | 23 | 22 – 177 600 экз. |
| 1911 | 24 | 21 – 163 150 экз. |
| 1912 | 34 | 32 – 171 240 экз. |
| 1913 | 33 | 30 – 199 100 экз. |
| 1914 | 27 | 24 – 170 150 экз. |
| 1915 | 34 | 31 – 198 500 экз. |
| 1916 | 29 | 24 – 118 400 экз. |

Поначалу эти книги издавались объемом от 16 до 32 страниц. Их содержание, как было сказано ранее, в основном было песенным. Также выпускалось множество сборников с публикацией пословиц, поговорок, сказок, мэзэков, баитов и других жанров.

После Октябрьской революции сбор, обработка, публикация, научное изучение фольклора было включено в плановый бюджет государства. В 1926 году создан Академический центр при Наркомпросе Татарстана. Его руководитель Галимджан Ибрагимов внес большой вклад в развитие процесса сбора и научного изучения фольклора. Примерно в это же время при

[1] Данные не претендуют на абсолютное соответствие истинному положению дел.

Академическом центре создается комиссия по фольклору, сотрудниками которой была написана очень подробная инструкция по сбору произведений народного творчества. Вскоре этот документ распространяют во все места проживания татар. По этому поводу Г. Ибрагимов и сам выступает в прессе. «На первый план нам необходимо выдвигать главный вопрос о сохранении литературы и языка – осуществлять научный подход к сбору, регистрации и упорядочению произведений фольклора, – акцентирует он в одной из своих статей, опубликованной в журнале «Безнең юл (Наш путь)» (1926. № 5–6. – С. 2). Там же приводятся важные методические советы: во время сбора ничего не изменять, указывать для каждого произведения информацию о том, где, когда и от кого оно было получено и пр. Отметив, что ранее полученный фольклор принадлежал казанским татарам, Г. Ибрагимов указал на необходимость сбора произведений народного творчества и у других этнических групп (касимовские татары, мишари, тюменские татары и др.).

К сбору фольклора для Академического центра активно подключились М. Курбангалиев, Г. Рахим, Х. Бадиги, М. Васильев.

В 20–30-х годах не остались в стороне от изучения фольклора и писатели. После первого съезда Союза писателей (1934), откликнувшись на призыв А. М. Горького, татарские писатели, члены Союза писателей Татарстана выезжали в ежегодные фольклорные экспедиции, по результатам которых выпускали различные сборники, проводили другие важные мероприятия. Изыскания писателей Г. Толымбая, А. Шамова, Г. Баширова, Н. Исанбета, А. Ахмета, М. Садри, Ш. Маннура, Х. Ярми и др. оставили глубокий след в фольклоре того периода. Помимо издания сборников и публикации статей в периодических изданиях, продолжались научные исследования фольклора.

В сороковых годах центром изучения татарского фольклора стал Институт языка, литературы и истории (в 1945 году он был введен в состав Казанского филиала Академии наук СССР). В 1945–1955 годах фольклорные экспедиции Института фронтально изучили все районы Татарстана. В последующие десятилетия собирался фольклор татар, проживающих в Кировской, Пензенской, Рязанской, Оренбургской,

Астраханской, Горьковской, Ульяновской, Куйбышевской областях и в республиках Мордовии, Марий Эл, Удмуртии. Во второй половине шестидесятых годов начался сбор произведений устного народного творчества у татар Сибири (Тюменская, Омская, Новосибирская области) и Урала (Пермский край, Свердловская, Курганская, Челябинская области). В результате фольклорный фонд Института пополнили около 1600 сказок, более 60 дастанов, примерно 600 преданий и легенд, 1300 мэзэков, более 100 коротких песен, около 2 тысяч исторических, лирических, обрядовых и игровых песен, более тысячи баитов и мунаджатов, около 20 тысяч пословиц и поговорок, около 5 тысяч загадок. Нужно отметить, что часть этой богатой сокровищницы пополнена материалами фольклорных экспедиций Казанского и Башкирского университетов, а также сведениями из частных коллекций.

Естественно, что столь пристальное плановое внимание к фольклору придало импульс выпуску новых сборников произведений народного творчества. В 1951 году увидела свет антология татарского фольклора «Татар халык иҗаты», подготовленная Г. Башировым, А. Шамовым, Х. Ярми, Х. Усмановым. Сборники «Татарские народные сказки» (в 2-х т.) (Г. Баширов, Х. Ярми), «Татарские народные пословицы» (в 3-х т.) (Н. Исанбет), «Баиты» (Х. Ярми), «Татарские народные песни» (И. Надиров), «Тысяча и один мэзэк» (Г. Баширов) и др., сопровождаемые содержательными вступительными статьями и научными комментариями, в пятидесятых-шестидесятых годах совершили настоящий прорыв в татарской фольклористике. Наконец, в 1976–1988 годах вышел в свет 12-томный свод, подготовленный фольклористами Института языка, литературы и искусств им. Г. Ибрагимова. Свод под общим названием «Татарское народное творчество» включает в себя сказки (3 тома), мэзэки, легенды и предания, дастаны, баиты, загадки, пословицы и поговорки, короткие песни, обрядовые и игровые песни, исторические и лирические песни. Татарское книжное издательство выпустило каждый том, сопровождаемый объемной вступительной статьей, а также комментариями и списком источников, тиражом 30 000 экземпляров. Над выпуском 12-томного свода активно

трудились фольклористы Института Х. Ярми, Х. Гатина, И. Надиров, Ф. Ахметова, Х. Махмутов, Л. Замалетдинов. В 1993 году подготовленный Р. Ф. Ягафаровым 13 том «Детский фольклор» завершил данную антологию.

За период с 1960 по 1990 годы увидели свет многочисленные научные статьи и авторские монографии. Вот некоторые из них: И. Надиров. «Народ и песня» (1961); Х. Ярми. «Поэтическое творчество татарского народа» (1967); Ф. Урманчеев. «Глас народа: Очерки об истории татарских баитов» (1974); Р. Мухаметзянов. «Обрядовое творчество приикских татар Башкортостана: свадебная поэзия» (1977); А. Г. Яхин, М. Х. Бакиров. «Опыт систематизации фольклорных жанров (Мэзэки, баиты)» (1979); Х. Махмутов. «Мал золотник, да дорог: особенности жанра загадки» (1980), Ф. Урманчеев. «Эпические сказания татарского народа» (1980); А. Г. Яхин, М. С. Магдеев. «Опыт систематизации татарского фольклора (Пословицы, загадки, песни)» (1982); Р. Мухаметзянов. «Обрядовое творчество приикских татар Башкортостана: календарная поэзия» (1982); Ф. Урманчеев. Героический эпос татарского народа» (1984); А. Яхин. «Система татарского фольклора» (1984); Р. Ягафаров. «Поэтические родники» (1985) и др. В качестве показателя научных успехов в изучении татарского фольклора следует отметить такие важные события, как защита 2 докторских и 9 кандидатских диссертаций.

* * *

Татарская фольклористика, развивавшаяся в течение XX столетия в разных направлениях, на рубеже веков поднялась на новую ступень. Фундаментальные успехи в этой области, начиная с 80-х годов и заканчивая современным этапом, тесно связаны с деятельностью отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, превратившегося в научный центр, определяющий основные направления исследований в татарской фольклористике. Это сбор произведений духовного наследия татар, проживающих в Республике Татарстан и других регионах Российской Федерации, научное исследование и анализ этнолокальных осо-

бенностей, изучение фольклора во взаимодействии с другими науками, издание образцов устного народного творчества, выявление национального своеобразия татарского фольклора, поиск общих признаков с фольклором других тюркских народов и пр.

В 1992 году руководителем отдела народного творчества Института языка, литературы и искусств им. Г. Ибрагимова назначают ученика Хамита Ярми – Фатиха Урманчеева, ставшего к тому времени известным ученым. Эта была пора большого внимания к теоретическим изысканиям, создавались и выпускались многочисленные научные труды, освещающие вопросы изучения отдельных жанров. Стоит обратить внимание на фундаментальные работы Ф. И. Урманчеева, И. Н. Надирова, Х. Ш. Махмутова, М. Х. Бакирова, Ф. В. Ахметовой, А. Х. Садековой, Р. Ф. Ягафарова, С. М. Гилязетдинова. Эти основательные и содержательные работы отличаются высоким научным уровнем в области исследования татарской мифологии, систематики жанров татарского фольклора.

В начале XXI века одной из актуальных проблем остается подготовка кадров. Ряды молодых ученых пополняются, в результате работы нового поколения исследователей одна за другой выпускаются фундаментальные монографии. В эту пору ученые К. М. Миннуллин, Л. Х. Мухаметзянова, И. Г. Закирова, Л. Х. Давлетшина, Л. Ф. Замалиева, Л. А. Кариева, И. И. Ямалтдинов ведут научные изыскания по различным направлениям татарской фольклористики. За последние тридцать лет в области татарской фольклористики защищено 6 докторских, 10 кандидатских диссертаций.

Сбор богатого духовного наследия татарского народа, в том числе произведений народного творчества остается востребованным делом и в наши дни. Благодаря системным усилиям Академии наук Татарстана, деятельность в области собирания и исследования татарского народного творчества вышла на новый уровень. Организуемые Институтом языка, литературы и искусств им. Г. Ибрагимова комплексные научные экспедиции стали отдельным направлением работы ученых-фольклористов. Новый этап в организации и проведении экспедиций начался с 2009 года по инициативе директора Института К. М. Мин-

нуллина. В ходе научных экспедиций был собран богатый фольклорный материал в районах Татарстана (13), регионах компактного проживания татар на территории Российской Федерации и за ее пределами (24). Систематизация собранных ранее и вновь привезенных материалов позволила начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» в серии «Из сокровищницы научных экспедиций». К 2022 году нашли своего читателя более 20 книг из этой серии. Огромным достижением этой работы стало распространение данных изданий в местах проведения полевых исследований, что позволило материалам вернуться на родину, к народу.

В последние годы наряду с исследованием, анализом и введением в научный оборот материалов, собранных во время экспедиции ведется работа по изучению накопленного в архиве Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова с 1940-х годов наследия, сопоставлению его с вновь поступившими данными, в том числе готовятся многочисленные новые научные труды. Одним из таких фундаментальных трудов является 25-томный свод «Татарское народное творчество» на татарском языке.

Многотомный труд включает в себя как ранее опубликованные материалы тринадцатитомного академического издания, так и некоторые образцы, не вошедшие в них, а также фольклорные жемчужины, найденные после выхода академических томов. Цель этой работы – вернуть народу духовное богатство, популяризировать его, оставить в истории, обобщить результаты многолетних научно-исследовательских работ, объединив многолетние находки в фольклоре в единое целое.

В результате этой работы в 2021 году увидел свет том «Мифология», в 2022 году – «Обрядовый фольклор»[1]. 25-томный фундаментальный сборник охватывает все жанры татарского народного творчества. В то же время продолжается работа по подготовке 15-томного издания «Татарское народное творче-

[1] Татар халык иҗаты: 25 томда. 2 т.: Йола фольклоры / [төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л. Х. Дәүләтшина]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2022. – 541 б.

ство» на русском языке. На сегодняшний день вышли в свет 9 томов этого многотомного труда, из них в 2022 году – том «Баиты»[1].

Кроме Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова изучением народных традиций, их быта, обычаев и обрядов занимаются ученые в стенах Казанского (Приволжского) федерального университета, Казанской консерватории им. Н. Жиганова, высших учебных заведений Уфы, Елабуги, Набережных Челнов, Тюмени, Тобольска, Республиканского центра развития традиционной культуры (ныне – Таткультресурсцентр) и др. Итоги комплексных научных экспедиций по районам Татарстана и в места компактного проживания татар публикуются в монографиях и научных сборниках, подготовленных в данных организациях.

Как видно из этого краткого обзора, сбор и изучение татарского народного творчества имеет достаточно длинную по времени, богатую по объему и содержанию историю[2] и перспективы.

---

[1] Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 9: Баиты. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2022. – 479 с.

[2] Об этом подробнее в следующих трудах: *Ярми Х.* Татар фольклорын туплау һәм өйрәнү тарихы // Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан, 1967. – Б. 9–82; *Мәһдиев М.* Совет чоры фольклористикасы // Фольклор жанрларын анализлау. – Казан, 1986. – Б. 27–35; *Урманчеев Ф.* Бүгенге татар фольклористикасының кайбер мәсьәләләре // Татар фольклорының хәзерге торышы. – Казан, 1988. – Б. 95–108; *Миңнуллин К. М.* Басма сүз һәм татар җырлары. – Казан, 2000. – 157 б.; *Закирова И. Г., Урманчеев Ф. И.* Эшләре – җыр, сүзләре – дастан (халык иҗаты бүлегенең 75 еллыгы уңаеннан) // Фәнни Татарстан. – 2014. – № 4. – Б. 80–88; *Ямалтдинов И. И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора / И. И. Ямалтдинов. – Казань, 2016. – 184 с.; *Закирова И. Г., Мөхәммәтҗанова Л. Х.* Халык җәүһәрләре сагында (Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге оешуга – 80 ел) // Туган җир. – 2019. – № 3. – Б. 182–194 и др.

## КЕРЕШ[1]

### Татар фольклорын җыю һәм өйрәнү тарихыннан

Борынгы төрки халыкларның, шул җөмләдән Идел буе төркиләренең авыз иҗаты үрнәкләре әле моннан мең еллар элек үк кәгазьгә теркәлә башлаган. Әйтик, 922 елда Идел буе Болгар дәүләтенә килгән гарәп илчелеге секретаре Ибне Фазлан язмаларында Казан татарларының бабалары булган болгарларның күп кенә йола-ышанулары, риваять-легендалары белән танышырга мөмкин. XI йөзнең атаклы тюркологы Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатит төрк» сүзлегендә (1072–1074) фольклор әсәрләре аеруча күп очрый. «Мин бу китапны... хикмәтле сүзләр, сәҗгъләр[2], мәкальләр, шигырьләр, рәҗаз[3] һәм нәсер дип аталган әдәби парчалар белән бизәдем», – дип яза М. Кашгари[4]. Бу әсәрләрне тасвирлап тормастан, шуны гына әйтик: алар арасында Идел турындагы җыр да, Казан татарларында безнең заманга кадәр сакланып калган Нух пәйгамбәр улы Яфәснең уллары Гази, Төрек, Алып хакындагы риваять тә бар. Сүзлектә теркәлгән 307 мәкаль һәм әйтемнең 120 гә якыны бүгенге көндә дә татар фольклорының җанлы репертуарында яшәвен дәвам итә. Еш кына борынгы һәм хәзерге текстларның сүзгә-сүз тәңгәллеге күзәтелә: Арслан карыса, сычган өтин

---

[1] Биредә «Татар фольклоры. Библиографик крсәткеч» китабының (1993) Ә. Кәримуллин һәм Х. Мәхмүтов тарафыннан язылган кереш мәкаләсе нигез итеп алынды һәм бүгенге көн таләпләреннән чыгып редакцияләнде. 1993 елда дөнья күргән күрсәткеч үз эченә 1612–1981 еллар аралыгын алганга күрә, татар фольклористикасының соңгы кырык ел эчендәге үсеш-үзгәреше мәкаләнең икенче өлешендә яктыртылды.

[2] Сәҗгъ – рифмалы проза.

[3] Рәзаҗ – батырларның сугышларда күрсәткән каһарманлыкларын тасвирлаучы шигъри әсәр.

[4] *Кошгарий Махмуд*. Туркий сүзлар девони (Девону луготит турк). – I т. – Тошкент, 1960. – Б. 44–45.

күдәзүр – Арыслан картайса, тычкан өнен күзәтер; Бар бакыр, йок алтун – Бар бакыр, юк алтын; Бөринең ортак, кузгунуң йыгач башында – Бүренеке уртак, козгынныкы агач башында; Ике кочңар башы бир ашычта бешмәс – Ике кучкар башы бер табакка сыймас; Көккә сагурса, йүзкә түшүр – Күккә төкерсә, битеңә төшәр һ.б.

XIII–XIV йөзләрдә Идел буенда һәм төркиләр (бигрәк тә Казан татарларының халык булып формалашуында зур роль уйнаган кыпчаклар) яшәгән башка кайбер урыннарда күп кенә сүзлекләр төзелгән булуы билгеле. Аларның хәзергәчә сакланып калганнары гына да дистәдән артык. Шулардан 1303 елда төзелгән Кодекс Куманикусны (Коман мәҗмугасын) шулай ук татар фольклор фәненең чишмә башы дип санарга җитәрлек нигез бар. Халык иҗаты әсәрләреннән биредә 46 табышмак теркәлгән. Алар тематик яктан да, шигъри төзелешләре, тел-тасвир чаралары белән дә безнең бүгенге табышмакларыбызга якын торалар, ә кайчакта хәтта текстуаль тәңгәл киләләр.

Аерма булса да тик кайбер архаик сүзләрдә генә күренә:

Көкчә ылагым кегендә семирир (Ол каун).
Күк ылагым күк үләндә ятып симерде (Карбыз).
Йазда йаулы кайыш йатыр (Ол йыландыр).
Яланда майлы каеш ятыр (Елан) һ.б.

Халык иҗаты үрнәкләре борынгы татар әдәбияты әсәрләрендә: Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (XIII йөз), Мәхмуд бине Гали Болгариның «Нәһҗел фәрадис» (1358), Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (XIV йөз), Сәйф Сараиның «Гөлстан бит төрки» (XIV йөз), Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (XIV йөз) һ.б. истәлекләрдә дә очрыйлар. Алар Казан, Ленинград һ.б. шәһәрләрнең китапханәләрендә саклanучы меңләгән иске татар кулъязмаларында да табылалар.

Татар фольклорына да мөнәсәбәте булган беренче басма хезмәт– Иероним Мегиссерның 1612 елда Лейпцигта дөнья күргән кыпчак теле грамматикасы һәм сүзлеге. Бу китапта тел үрнәкләре итеп яисә уку өчен бирелгән текстлар арасында 220 дән артык мәкаль һәм әйтем бар. Шундый ук хәл

Д. Франчиско-Мари Магджио грамматикасында (Рим, 1643) да күзәтелә. Халык афоризмнары, риваять-легендалар Европа сәяхәтчеләренең һәм тарихчыларының XVI–XVIII йөзләрдә төрки-татарлар турында язган хезмәтләрендә дә сакланып калган.

Россиядә татар фольклоры әсәрләрен язып ала башлау XVIII гасырга туры килә. 1725 елда Петербургта Фәннәр академиясе оештырылып, аның тарафыннан империядә яшәүче төрле халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү максатында экспедицияләр үткәрелә башлагач, фольклор әсәрләре үз илебездә басыла торган хезмәтләргә дә үтеп керә. Г. Ф. Миллер, П. С. Паллас, И. И. Лепехин, Н. П. Рычков, М. Д. Чулков хезмәтләрендә, башка халыкларныкы белән беррәттән, татарларның да җыр-биюләре, уеннары, халык бәйрәмнәре, легендалары турында мәгълүматлар урын ала. Хәлбуки болар әле татар фольклорын туплау түгел, ә халыкның этнографиясен тасвирлауга ярдәм итүче иллюстратив үрнәкләр генә иделәр.

Татар халык иҗаты әсәрләрен махсус рәвештә туплый башлаучыларның берсе Иван Добровольский булды дисәк ялгыш булмастыр. Ул 1816 елда Әстерханда литография ачып, «Азиатский журнал» дигән басма чыгаруга керешә. Журнал битләрендә төрки халыкларның, бигрәк тә татарларның халык җырлары текстлары һәм ноталары белән басыла башлый.

XIX йөзнең утызынчы еллары башында И. Снегирев, В. Романович, илленче еллар уртасында Н. Берг хезмәтләрендә татар фольклоры үрнәкләре дә (җырлар, мәкальләр, әйтемнәр) дөнья күрә.

Казанда университет ачылу нәтиҗәсендә биредә Идел буе һәм Көнчыгыш халыкларының тарихын, әдәбиятын, телен, культурасын өйрәнү эше шактый алга китә. Ә 1878 елда университет каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оештыру, аның «Известия»ләрен чыгара башлау бу эшнең тагын да киңрәк масштаблар алуына китерә. Университет галимнәре, фәнни җәмгыять членнары К. Фукс, И. Готвальд, А. Артемьев, И. Н. Березин, В. В. Радлов, Н. Ф. Катанов һ.б. татар фольклорын җыю һәм өйрәнүгә сизелерлек өлеш кертәләр.

XIX йөзнең беренче яртысында татар халык иҗаты үрнәкләрен туплау ягыннан иң кыйммәтле чыганак булып Мартиньян Ивановның 1842 елда Казан университеты типографиясендә чыккан «Татарская хрестоматия»се саналырга хаклы. Оренбург Неплюев кадет корпусында татар теле укытучысы булып эшләгән М. Иванов бу хезмәтендә 128 мәкаль, 70 җыр, 34 табышмак һәм 8 әкият тексты урнаштыра.

Узган йөзнең икенче яртысында, Казаннан тыш, Себер, Урал, Әстерхан, Пенза, Рязань, Саратов татарларының авыз иҗатын барлау эше дә дәвам итә, Россия Фәннәр академиясенең һәм аерым губерналарда чыгып килүче географик җәмгыять бүлекләренең «Известия»ләрендә шушы темага караган материаллар басылгалап тора, губерна «Ведомость»ларында да күзәтүләр урнаштырыла.

Бу чорда татар фольклоры буенча чыккан хезмәтләр арасында Р. Г. Игнатьев, Н. Костров, И. Покровский, В. Витевский, С. Г. Рыбаков туплаган материаллар аеруча бай һәм әһәмиятле.

Татар фольклорын җыю һәм бастыру юнәлешендә узган йөзнең икенче яртысында, шулай ук XX гасырда кайбер чит ил тюркологлары башкарган эш тә тәкъдир ителүгә лаек. Габор Балинт (Будапешт, 1875), Герман Вамбери (Лейпциг, 1885), Һейкки Паасонен (Хельсинки, 1901) һ.б. тарафыннан чыгарылган җыентыклар әнә шундый мисаллар булып тора.

1800 елда Казанда беренче татар типографиясе ачылу, татар матбагачылыгы барлыкка килү халык иҗаты әсәрләрен туплау һәм бастырып чыгару эшендә татарларның үзләре дә киңрәк катнашуга китерә. Инде халык әкияте булып киткән «Сәйфелмөлек кыйссасы» 1807 елда берьюлы ике басмада аерым китап итеп бастырыла, 1829 елда «Йосыф кыйссасы», 1845 елда Хуҗа Насретдин мәзәкләре, 1848 елда «Сөләйман кыйссасы» дөньяга чыга, аннан алар һәр елны диярлек басылып киләләр. 1852 елда Габдеш Ваһаповның «Русча-татарча әлифба»сы дөнья күрә. Соңыннан «Үзи-үзидән өйрәткеч» исеме белән чыга башлаган бу хезмәтнең революциягә кадәр егермедән артык басмасы чыга. Аның һәр басмасында татар халык җырлары, мәзәкләр, әкиятләр, мәкальләр, әйтемнәр басылып килә. 1869 елда

Г. Ваһапов «Җырлар» исеме белән татар халык җырларының беренче җыентыгын нәшер итә. Г. Мәхмүтов, С. Кукляшев, М. Бикчурин һ.б. татар укымышлылары да үзләренең татар теленә багышланган хезмәтләрендә фольклор әсәрләрен киң файдаланып киләләр.

XIX йөзнең икенче яртысында татар фольклорын туплау, өйрәнү, бастырып чыгару эшенә Г. Фәезханов, М. Салихов, Т. Яхин, Г. Минеев, Ф. Халиди һ.б. татар зыялылары да шактый өлеш кертәләр. 1870–1880 еллардан башлап төзүчеләре, язып алучылары күрсәтелмәгән дистәләрчә «кыйссалар», «ләтаифлар», «хикәятләр» җыентыклары басыла башлый. Татар теленә Көнчыгыш халыклары фольклор әсәрләрен тәрҗемә итү көчәя. Атаклы «Тутый намә», «Кәлилә вә Димнә» җыентыклары, «Мең дә бер кичә»нең тулы циклы дөнья күрә. Әгәр 1807–1870 еллар арасында фольклор әсәрләре елына берике-өч тапкыр гына нәшер ителсә, 1880 еллардан соң андый басмалар ел саен диярлек дистәләп чыгып тора, безнең мәгълүматлар буенча 1880 елда – 7, 1881 елда – 7, 1882 елда – 4, 1883 елда – 12, 1887 елда – 9, 1888 елда – 10, 1889 елда – 15, 1896 елда – 24, 1897 елда – 18, 1899 елда 20 фольклор җыентыгы басыла. Аларның уртача тиражы 2400, 5000, 10 000 данә тәшкил итә.

Бу чорда татар фольклористикасы тарихында бөек мәгърифәтче һәм энциклопедист-галим Каюм Насыйри аеруча тирән эз калдыра. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге, Х. Ярми билгеләп үткәнчә, нигездә өч юнәлештә барды. Беренчедән, ул татар фольклорын турыдан-туры халыкның үз авызыннан язып алып, тупланган материалларның иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур игътибар бирде. Икенчедән, үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, дөньяга карашы белән башка халыкларны таныштыру максатында, К. Насыйри татар халык иҗаты әсәрләренең иң характерлы үрнәкләрен рус телендә нәшер итүгә күп көч куйды. Өченчедән, мәгърифәтче-галим Көнчыгыш фольклорын җентекләп өйрәнде һәм аның күп кенә үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итеп бастырды[1].

---

[1] *Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. – Казан, 1967. – Б. 30–31.

Әлбәттә, беренче юнәлеш дигәнне, ягъни фольклорны җыю һәм бастыруны киңрәк һәм тирәнрәк мәгънәдә аңларга кирәк. Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм матбугатка чыгару процессында К. Насыйри аларны билгеле бер системага салды, жанрларга аерды, бу жанрларга билгеләмәләр, ә күп кенә әсәрләргә искәрмәләр, аңлатмалар бирде. Үзенең элгәрләре һәм замандашлары белән чагыштырганда, К. Насыйриның хезмәтләре, бер яктан, материалның күләме һәм сыйфаты, фольклорның барлык жанрларын да диярлек үз эчләренә алулары белән аерылып тордылар. Икенче яктан, фольклорны җыю һәм бастыру, аны лингвистик, тарихи-этнографик хезмәтләрдә, хрестоматияләрдә, уку китапларында файдаланудан тыш (күргәнебезчә, боларны аның элгәрләре дә эшләделәр), Каюм Насыйри халык иҗатын махсус фән буларак өйрәнә башлауга нигез салды. «Каюм Насыйри, – дип язды Хуҗа Бәдигый, – Казан татарларының үз араларыннан чыккан һәм... халык җырларын, бәетләрен, такмакларын, көйләрен... өйрәнүне аерым бер гыйлем санап, шул бабда ишеткән, күргән материалларының берсен дә югалтмыйча дикъкатьләп өйрәнә һәм җыя барган үз галимебездер»[1].

Икенче төрле әйткәндә, халык иҗаты әсәрләрен җыю, бастыру этабыннан аларны фәнни нигездә өйрәнүгә күчү, ягъни татар фольклористикасының мөстәкыйль фән буларак формалаша башлавы нәкъ менә К. Насыйри эшчәнлеге белән бәйләнгән иде.

XX йөз башында, бигрәк тә 1905–1907 елгы революция нәтиҗәсендә татар телендә фольклор әсәрләрен басу зур тизлек белән үсә башлады. Чөнки татар типографияләре саны артты, китап басу өчен дистәләгән нәшриятлар барлыкка килде. Бу нәшриятлар, китапка ихтыяҗның зур булуыннан файдаланып, кулларына ни эләксә, шуны диярлек басуга керештеләр. Менә шул шартларда, күләме белән 16, 24, 32 биттән торган җыр җыентыклары бер-бер артлы «пешеп» кенә торалар. Шуның белән беррәттән, бу чорда татар халык иҗаты әсәрләрен

[1] *Бәдигый Х.* К. Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлындагы хезмәтләре // Каюм Насыйри мәҗмугасы. – Казан, 1922. – Б. 104.

тулырак планда, фәнни нигездә җыючылар да күренә башлый. Беренче чиратта, Ш. Рәхмәтуллин, Ш. Хәмидуллин, Г. Арсланов, Г. Рәшиди, Ф. Туйкин, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Х. Бәдигый, А. Белеш, Г. Рәхим һ.б. шактый зур эш башкаралар.

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай халык җәүһәрләре белән тирән кызыксына, аларны туплауга, өйрәнү, бастырып чыгаруга зур өлеш кертә. Г. Тукай, Г. Ибраһимовлар, К. Насыйриның традицияләрен дәвам итеп, фольклорны фәнни яктан өйрәнү эшенә дә игътибар бирәләр.

1907–1916 елларда татар халык иҗатын туплауның нинди адымнар белән үсүе татар телендә чыккан фольклор басмалары саныннан[1] да ачык күренә:

| Еллар | Басмалар саны | Тиражы ачыкланган басмалар һәм аларның гомуми тиражы |
|---|---|---|
| 1907 | 20 | 18 – 90 000 данә |
| 1908 | 21 | 19 – 125 800 данә |
| 1909 | 34 | 30 – 234 400 данә |
| 1910 | 23 | 22 – 177 600 данә |
| 1911 | 24 | 21 – 163 150 данә |
| 1912 | 34 | 32 – 171 240 данә |
| 1913 | 33 | 30 – 199 100 данә |
| 1914 | 27 | 24 – 170 150 данә |
| 1915 | 34 | 31 – 198 500 данә |
| 1916 | 29 | 24 – 118 400 данә |

Күләме ягыннан бу басмалар башлыча 16–32 бит тәшкил итәләр. Аларның зур күпчелеген, алда әйтелгәнчә, җырлар алып тора. Мәкальләр, әйтемнәр, әкиятләр, мәзәкләр, бәетләр һәм башка жанрлар буенча да байтак җыентыклар бар.

Октябрь революциясеннән соң татар халык иҗатын җыю, эшкәртү, матбугатка чыгару, фәнни нигездә өйрәнү дәүләт оешмаларының бюджет планына кертеп алып барыла башлады. 1926 елда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршында Гыйльми Үзәк оештырылды. Аның җитәкчесе Галимҗан

[1] Мәгълүматлар абсолют тулылыкка дәгъва итмиләр.

Ибраһимов фольклорны җыю һәм өйрәнү эшен оештыруга да гаять зур өлеш кертте. Шушы чорда Гыйльми Үзәк янында фольклор комиссиясе төзелде, халык иҗатын җыю буенча бик җентекле инструкция хәзерләнеп, татарлар яши торган төрле урыннарга таратылды. Г. Ибраһимов бу мәсьәлә буенча үзе дә матбугатта чыгыш ясады. «Бездә халык әдәбиятын җыю, тикшерү, тәртипләү эше – тел-әдәбият мәсьәләләренең бик кирәкле тармагы буларак, хәзерге көндәге гыйльми-әдәби эшләребезнең алдынгыларыннан итеп мәйданга куелырга тиешледер», – дип басым ясап язды ул «Безнең юл» журналында басылган бер мәкаләсендә (1926. № 5–6. – Б. 2). Шунда ук әһәмиятле методик киңәшләр бирелә: җыйган вакытта һич нәрсәне үзгәртмәү, һәр әсәрнең кайдан, кемнән язып алынганын күрсәтү һ.б. Моңа кадәр җыелган материалларның башлыча Казан татарларыныкы булуын әйтеп, Г. Ибраһимов татар халкының башка этник төркемнәренең (Касыйм татарлары, мишәрләр,төмәннәр һ.б.) фольклорын җыю белән шөгыльләнү бурычын да көн тәртибенә куйды.

Гыйльми Үзәкнең фольклор буенча эшчәнлегендә М. Корбангалиев, Г. Рәхим, Х. Бәдигый, М. А. Васильевлар да актив катнаштылар.

Әлбәттә, 20–30 нчы елларда халык иҗатын өйрәнүдән язучылар да читтә калмадылар. Совет язучыларының беренче съездыннан соң (1934) А. М. Горькийның чакыруына җавап итеп, Татарстан Язучылар союзы даими фольклор экспедицияләре оештыру, төрле җыентыклар нәшер итү һ.б.ш. мөһим чаралар үткәрде. Язучылардан Г. Толымбай, А. Шамов, Г. Бәширов, Н. Исәнбәт, А. Әхмәт, М. Садри, Ш. Маннур, Х. Ярми һ.б. бу чор фольклористикасында тирән эз калдырдылар. Җыентыклар төзеп бастырудан тыш, аларга бирелгән кереш мәкаләләрдә, вакытлы матбугат чыгышларында фольклор турында фәнни тикшеренүләр дә алып барылды.

Кырыгынчы еллардан башлап татар фольклорын өйрәнү үзәге булып Тел, әдәбият һәм тарих институты әверелде (1945 елда Институт СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составына кертелде). 1945–1955 елларда Институт оештырган фольклор экспедицияләре Татарстанның барлык

районнарын фронталь өйрәнеп чыктылар. Алдагы ун елда Киров, Пенза, Рязань, Оренбург, Әстерхан, Горький, Ульянов, Куйбышев өлкәләрендә, мордва, мари, удмурт республикаларында яшәүче татарлар фольклоры җыйналды. Алтмышынчы елларның икенче яртысыннан Себер татарларының (Төмән, Омск, Новосибирск өлкәләре) һәм Урал татарларының (Пермь, Свердловск, Курган, Чиләбе өлкәләре) авыз иҗатын җыю башланды. Нәтиҗәдә Институтның фольклор фондында 1600 гә якын әкият, 60 тан артык дастан, 600 чамасы риваять һәм легенда, 1300 ләп мәзәк, 100 меңнән артык кыска җыр, 2 меңгә якын тарихи, лирик, йола һәм уен җырлары, меңнән артык бәет һәм 1 мөнәҗәт, 20 меңләп мәкаль һәм әйтемнәр, 5 меңгә якын табышмак тупланды. Бу бай хәзинә эчендә аерым кешеләр тапшырган коллекцияләр вә Казан һәм Башкорт университетлары уздырган фольклор экспедицияләре материаллары барлыгын әйтергә кирәк.

Табигый ки, фольклорны шулай киң планда туплау халык иҗаты җыентыкларын бастыруга яңа этәргеч бирде. 1951 елда Г. Бәширов, А. Шамов, Х. Ярми һәм Х. Усманов әзерләгән «Татар халык иҗаты антологиясе» дөнья күрде. Ике китаптан торган «Татар халык әкиятләре» (Г. Бәширов, Х. Ярми), өч томлык «Татар халык мәкальләре» (Н. Исәнбәт), «Бәетләр» (Х. Ярми), «Татар халык җырлары» (И. Надиров), «Мең дә бер мәзәк» (Г. Бәширов) һ.б. шундый күләмле җыентыклар (аларда эчтәлекле кереш мәкаләләр, фәнни искәрмәләр дә бирелгән) илленче-алтмышынчы еллар татар фольклористикасының зур казанышы булдылар. Ниһаять, 1976–1988 еллар дәвамында татар халык иҗаты әсәрләренең Г. Ибраһимов исемендәге институт фольклорчылары әзерләгән 12 томлык җыелмасы дөнья күрде. «Татар халык иҗаты» дигән гомуми исемдәге бу басма әкиятләр (3 китап), мәзәкләр, риваятьләр һәм легендалар, дастаннар, бәетләр, табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, кыска җырлар, йола һәм уен җырлары, тарихи һәм лирик җырлар томнарыннан тора. Татарстан китап нәшрияты бу томнарны 30 ар мең тираж белән бастырып чыгарды, һәр том күләмле кереш мәкалә һәм искәрмәләр, чыганаклар күрсәткечләре белән

тәэмин ителгән. 12 томлыкны әзерләүдә Институт фольклорчылары Х. Ярми, Х. Гатина, И. Надиров, Ф. Әхмәтова, Х. Мәхмүтов, Л. Җамалетдиновлар аеруча актив катнашты. 1993 елда Р. Ф. Ягъфәров әзерләгән «Балалар фольклоры» томы унөченче том булып бу җыелманы йомгаклады.

1960–1990 еллар арасында татар халык иҗатын тикшерүгә багышланган күп санлы фәнни мәкаләләр һәм аерым монографияләр дөнья күрде. Менә аларның кайберләре: И. Надиров. Халык һәм җыр (1961); Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты (1967); Ф. Урманчеев. Халык авазы: Татар халык бәетләре тарихыннан очерклар (1974); Р. Мөхәммәтҗанов. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: Туй поэзиясе (1977); А. Г. Яхин, М. Х. Бакиров. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәзәкләр, бәетләр) (1979); Х. Мәхмүтов. Кечкенә дә төш кенә: Табышмакларның жанр үзенчәлекләре (1980), Ф. Урманчеев. Эпические сказания татарского народа (1980), А. Г. Яхин, М. С. Мәһдиев. Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе (Мәкаль, табышмак, җырлар) (1982); Р. Мөхәммәтҗанов. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: Календарь поэзия (1982); Ф. Урманчеев. Героический эпос татарского народа (1984); А. Яхин. Система татарского фольклора (1984); Р. Ягъфәров. Шигърият чишмәләре (1985) һ.б. Татар фольклорын фәнни өйрәнүдәге уңышларның тагын бер мөһим күрсәткече сыйфатында 2 докторлык һәм 9 кандидатлык диссертацияләре яклануын да әйтергә кирәк.

* * *

XX гасыр дәвамында төрле юнәлешләрдә үсеп ныгыган татар фольклористикасы фәне гасыр чигендә яңа баскычка күтәрелә. Әлеге фәннең 1980 еллардан башлап бүгенге көнгә кадәрге нәтиҗәләре турыдан-туры татар фольклорының теоретик нигезен, төп юнәлешләрен билгеләүче фәнни үзәк буларак формалашкан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге эшчәнлеге белән бәйле. Бу – Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең төрле регионнарында яшәүче татар халкының

рухи мирасын туплау, фәнни яктан тикшерү һәм анализлау, фольклорның этнолокаль үзенчәлекләрен, башка фәннәр белән бәйләнешләрен өйрәнү, халык иҗаты әсәрләрен бастырып чыгару, татар фольклорының милли үзенчәлекләрен, аның төрки халыклар фольклоры белән уртак якларын өйрәнү һ.б.

1992 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге җитәкчесе итеп Хәмит Ярминең шәкерте, ул вакытка күренекле галим булып җитлеккән Фатих Урманчеев билгеләнә. Бу чорда теоретик мәсьәләләрне тикшерүгә зур игътибар бирелә, аерым жанрларны өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр дөнья күрә. Биредә Ф. И. Урманчеев, И. Н. Надиров, Х. Ш. Мәхмүтов, М. Х. Бакиров, Р. Ф. Ягъфәров, С. М. Гыйләҗетдинов, А. Х. Садыйкова, Ф. В. Әхмәтованың җитди хезмәтләренә игътибар юнәлтү зарури. Тирән һәм киң эчтәлекле бу хезмәтләр татар халкының мифологиясен, татар фольклорының жанрлар системасын һәм аның төрки халыклар мәдәниятендә тоткан урынын фәнни югарылыкта өйрәнүләре белән аерылып тора.

XXI гасыр башында гаять актуаль проблемаларның берсе булып кадрлар әзерләү мәсьәләсе кала. Яшь галимнәр сафы тулылана, яшьрәк буын галимнәрнең бер-бер артлы яңадан-яңа фундаменталь монографияләре дөнья күрә. Бу чорда К. М. Миңнуллин, Л. Х. Мөхәммәтҗанова, И. Г. Закирова, Л. Х. Дәүләтшина, Л. Ф. Замалиева, И. И. Ямалтдинов, Л. А. Кариева кебек галимнәр татар фольклористикасының төрле юнәлешләре буенча эш алып бара. Гомумән алганда, соңгы утыз ел эчендә «фольклористика» белгечлегенә караган 6 докторлык, 10 кандидатлык диссертациясе яклана.

Татар халкының бай рухи мирасын, шул исәптән халык иҗатын җыйнау эше хәзерге вакытта да дәвам итә. Татарстан Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар халык авыз иҗатын академик дәрәҗәдә барлау һәм өйрәнү эше яңа баскычка күтәрелә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан уздырылган комплекслы фәнни экспедицияләрдә фольклорчы галимнәр эшчәнлеге аерым бер юнәлеш рәвешен ала. Экспедицияләр эшендә

яңа этап Институт директоры К. М. Миңнуллин инициативасы белән 2009 елдан башланып китә. Экспедицияләр дәвамында Татарстан Республикасы районнарында (13 район), Россия Федерациясе һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең (24 регион) фольклор мирасы туплана. Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны берләштерү «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. 2022 елга әлеге сериядә чыккан егермедән артык китап укучыга барып иреште. Хезмәтнең иң зур әһәмияте дип ул китапларның экспедиция эшләгән регионнарга да таратылуын, ягъни рухи мирасның кире халыкка кайтарылуын күрсәтергә мөмкин.

Соңгы елларда, экспедициядә җыелган материалларны тикшерү, анализлау, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940 еллардан башлап туплана килгән мирасны барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру эше дә башкарыла, шул җирлектә күпсанлы яңа фәнни хезмәтләр әзерләнә. «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгы – шундыйларның берсе.

Chadwick. The growth of literature. – Vol. III. – Cambridge. – 1940. – P. 3–226.

История изучения устного творчества тюркских народов, в частности о фольклоре астраханских и сибирских татар.

1941

1166. Гали Хәсән, төз., җыючы. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан. – 1941. – 64 б. – 5000.

Җыентык урта яшьтәге мәктәп балалары өчен, М. Маминның «Мәкальләр һәм әйтемнәр» дигән сүз башы белән.

Рец.: Әхмәт А. // Яшь сталинчы. – 1941. – 16 май; Кабиров Г. // Сов. әдәбияты. – 1941. – № 10. – Б. 64–70.

1167. Исәнбәт Нәкый, җыючы, төзүче. Табышмаклар. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 196 б. – 6065.

1468 табышмак һәм аларның җаваплары. Текстлар тематик бүленештә, 2–28 битләрдә Н. Исәнбәтнең «Табышмакларыбыз турында» дигән мәкаләсе.

1168. Исәнбәт Н., җыючы, төзүче. Татар халкының балалар фольклоры. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 188 б. – 10 070.

Төзүченең «Балалар фольклорын өйрәнү һәм аңа классификация» дигән кереш мәкаләсе белән. Эчтәлеге: I. Бишек һәм аның тирәсе. (Җырлар. Кузгаткыч һәм мавыктыргычлар). II. Табигатькә эндәш һәм ияртүләр. III. Уен һәм фольклор (Уеннар. Җырлар). IV. Әйтешүләр. V. Такмаклар. VI. Җырлар. VII. Юанычлар һәм күңел ачкыч такмаклар. VIII. Сатиралар. IX. Пародияләр. X. Алдавыч әкиятләр. XI. Тизәйткечләр һәм чәбәкләштергечләр.

1169. Халиди Ф., төз., эшкәртүче. Мең дә бер сәхәр. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 152 б. – 10 070.

Халык әкиятләре текстлары. Л. Җәләйнең «Сүз башы» белән.

Рец.: Г. Мөхәммәт // Сов. әдәбияты. – 1941. – № 9. – Б. 90–91.

1170. Госман Х. Г. Тукайның фольклордан файдалануы // Яшь сталинчы. – 1941. – 16 апр.

1171. Гомәров А. Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының поэтик стилистикасы // Кыз. Татарстан. – 1941. – 28 февр.

1172. Җиһаншин Вәли. Халык җырчысы җыры // Кыз. Татарстан. – 1941. – 5 март.

Текст.

1173. Кызыл Армия турында халык җырлары // Азат хатын. – 1941. – № 2. – Б. 5.

Текстлар.

1174. Садри Г.-Х. һәм Ярми Х., җыючылар. Оборона җырлары // Сов. әдәбияты. – 1941. – № 10. – Б. 22.

Татар халык җырлары (текстлар).

1175. Хуҗа Насретдин әкиятләре: Хуҗа һәм күлмәк. – Итәкне акылга утырту. – Балык булып карау // Пионер каләме. – 1941. – № 1. – Т.б. 4.

Мәзәкләр (текстлар).

1176. Хуҗа Насретдин әкиятләре: Бозау үчен сыердан алган. – Иләккә су тутыру. – Егет сүзе бер булыр. – Урынлы тавыш // Пионер каләме. – 1941. – № 2. – Т.б. 4.

Мәзәкләр (текстлар).

1177. Хуҗа Насретдин әкиятләре: Бүген айның кырык бере. – Хуҗаның ике киленне хөкем итүе // Пионер каләме. – 1941. – № 3. – Т.б. 4.

Мәзәкләр (текстлар).

1178. Шауласын, яңгырасын безнең җыр: Халык җырлары // Азат хатын. – 1941. – № 8. – Б. 2.

Текстлар.

1179. Ярми Х., Бәшир Г. һәм Маннур Ш. Әкиятләр һәм риваятьләр // Сов. әдәбияты. – 1941. – № 1/2. – Б. 71–81.

Түбәндәге әкиятләр һәм риваятьләрнең текстлары да китерелә: Батыр командир. – Буденный. – Безнең авыл. – Ни чәчсәң, шуны урырсың. – Кара таяк. – Зирәк килен. – Песәй әкияте. – Батыр тегүче әкияте.

1180. Әмир М. Әкият сатучылар турында // Кыз. Татарстан. – 1941. – 19 янв.

Татар халык иҗаты буенча язылган кайбер әсәрләр турында.

1181. Садри М. Татар халкының җыр җәүһәрләре // Кыз. Татарстан. – 1941. – 1 февр.

Мәкалә.

## 1942

1182. Татар халык иҗаты җыентыгы // Кыз. Татарстан. – 1942. – 9 апр.

Чыгаруга әзерлек турында.

1183. Шамов Афзал. Халык җырлары турында // Сов. әдәбияты. – 1942. – № 6. – Б. 72–82.

1184. Ярми Х. Сугыш бәетләре // Сов. әдәбияты. – 1942. – № 3. – Б. 55–59.

Мәкалә.

1185. Сказка о трех талисманах. – Три дочери // Сказки народов Советского Союза. – М.-Л.: Детгиз, 1942. – С. 110–112.

Татарские народные сказки. В русском переводе.

## 1943

1186. Агишев Я., Ключарев А. һәм Разин Г., төз. Җырлар. – Казан: Татгосиздат, 1943. – 86 б. – 15 116.

Ленин комсомолының 25 еллыгы хөрмәтенә чыгарыла. Халык һәм шагыйрьләр җырлары.

Рец.: Гафи // Сов. әдәбияты. – 1943. – № 11. – Б. 80–81.

1187. Гали И. Тукай җырчы һәм музыка сөюче // Сов. әдәбияты. – 1943. – № 4. – Б. 36–38.

Г. Тукайның халык иҗаты әсәрләрен җыюы турында да.

1188. Әхмәт солдат. Хуҗа Насретдин мәзәкләре // Сов. әдәбияты. – 1943. – № 8. – Б. 77–79.

Ватан сугышы темасына караган 8 мәзәк тексты. Әхмәт солдат – Абдулла Әхмәтнең псевдонимы.

## 1944

1189. Камыр батыр: (Татар халык әкияте). – Казан: Татгосиздат, 1944. – 16 б. – 15 185.

Әкият тексты. Балалар өчен массовый басма.

1190. Кәҗә белән бүре: (Татар халык әкияте). – Казан: Татгосиздат, 1944. – 8 б. – 15 185.

Әкият тексты. Балалар өчен массовый басма.

1191. Гыйззәт Т. Юл язмалары // Сов. әдәбияты. – 1944. – № 7/8. – Б. 61–70.

Донбасс татарлары җырлары, бәетләре турында да (текстлар белән).

1192. Тарихи чынлык өчен // Сов. әдәбияты. – 1944. – № 10. – Б. 3–8.

«Идегәй» дастаны турында.

1193. Татар халык эпосы «Идегәй»нең русчага тәрҗемәсе // Кыз. Татарстан. – 1944. – 11 июнь.

## 1945

1194. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1945. – 188 б.

«Әбүгалисина кыйссасы», «Кырык вәзир кыйссасы», «Җәваһирелхикәят», «Фәвакиһел-җөләса», «Кырык бакча», «Җыен бәете», «Каюм Насыйриның календарьлары», «Буш вакыт» һ.б. әсәрләреннән өзекләр һәм аларда басылган әкиятләр, мәзәкләрдән үрнәкләр бирелгән.

1195. Бакый Халид. Әбүгалисина кыйссасы турында // Сов. әдәбияты. – 1945. – № 3/4. – Б. 80–82.

К. Насыйри эшкәрткән, халыклашкан әкият тарихыннан.

1196. Гайнуллин М. Тукай һәм халык иҗаты // Сов. әдәбияты. – 1945. – № 12. – Б. 57–63.

1197. Ярми Х. Татар халык иҗатында Ленин-Сталин образы // Кыз. Татарстан. – 1945. – 17 янв.

## 1946

1198. Бөек еллар тавышы. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 104 б.

Басманың ахырында «Халык җырлары» текстлары китерелә.

1199. Гөлчәчәк. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 16 б. – 10 195.

Әкият тексты. Балалар өчен массовый басма.

1200. Разин Г. һәм Ярми Х., төз. Татар халык әкиятләре / СССР ФА КФ, Тел, әдәбият һәм тарих институты. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 319 б. – 1 китап.

«Төзүчеләрдән» дигән сүз башы белән. Әкиятнең кайдан, кайчан, кем тарафыннан язып алынуы турында белешмәләр бирелгән.

1201. Тизәйткечләр. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 11 б. – 12 195.

Балалар фольклоры (тел күнекмәләре үрнәкләре).

1202. Тукай Г. Халык әдәбияты [М. Гайнуллинның «Тукай Һәм халык иҗаты» дигән мәкаләсе белән]. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 100 б. – 30 195.

Аннотациясе 1917 елгы басма тасвирламасында.

1203. Ярми Х., төз. Табышмаклар. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 11 б. – 25 195.

Нәниләр өчен җыентык.

1204. Әкиятләр. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 11 б.

Нәниләр өчен җыентык.

1205. Мусин Исмәгыйль. Курай тавышы // Сов. әдәбияты. – 1946. – № 5. – Б. 92–96.

Халык музыка коралы курай тарихыннан.

1206. Шамов А. Батырлар даны мәңге яши // Сов. әдәбияты. – 1946. – № 9. – Б. 110–115.

Бәетләр турында.

1207. Ярми Х. һәм Разин Г., җыючылар. Бөек Ленин һәм Сталин турында. Туган ил һәм батыр Кызыл Армия турында [Җырлар]. Җиңү байрагы [Бәет сыман әсәр] // Сов. әдәбияты. – 1946. – № 5. – Б. 56–57.

Текстлар.

1208. Ярми Х. һәм Разин Г. Ватан сугышы фольклоры // Сов. әдәбияты. – 1946. – № 5. – Б. 52–54.

Мәкалә.

1209. Ярми Х. Тукай һәм халык иҗаты // Кыз. Татарстан. – 1946. – 15 июнь.

## 1947

1210. Ак бүре: Татар халык әкияте. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 62 б. – 10 165.

Әкият тексты. Балалар ачен массовый басма.

1211. Ярми Х., төз. Әкиятләр. – Казан: Татгосиздат, 1947. – 62 б. – 5000.

Нигездә татар халык әкиятләреннән тора. Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен чыгарылган басма.

Рец.: Бакир Г. // Сов. әдәбияты. – 1940. – № 12. – Б. 109–110.

1212. Аю белән бабай. – Кәҗә белән бүре. – Төлке белән бүре. – Зур шалкан. – Аю белән бабай (Татар халык әкиятләре). – Табышмаклар (Текстлар, җаваплары) // Нәниләргә бүләк. – Казан: Татгосиздат, 1947. – Б. 12, 126, 128, 144–146.

Текстлар.

1213. Татар фольклорын өйрәнү // Кыз. Татарстан. – 1947. – 16 май.

Фольклор экспедициясенә әзерләнү һәм Тел, әдәбият һәм тарих институтының бу өлкәдәге эшләре турында.

1214. Татар фольклорын өйрәнү // Сов. әдәбияты. – 1947. – № 5. – Б. 118.

Тел, әдәбият һәм тарих институты экспедициясе турында информация.

1215. Өч кыз: Татар халык әкияте // СССР халыклары әкиятләре. – Казан: Татгосиздат, 1947. – Б. 70–71.

Текст.

1216. Бертельс Е. Э. К вопросу о традиции в героическом эпосе тюркских народов // Сов. востоковедение. – 1947. – № 4. – С. 73–79.

1217. Песни приволжских татар // Глоба А. Песни народов СССР. – М.: ОГИЗ, 1947. – С. 571–586, 791–792.

В русском переводе приведены тексты 14 татарских сюжетных песен: «Колыбельная», «Голубая шаль», «За конями белый след...», «Угрюм и черен лес...», «Новое платье», «Ключ», «Серп как месяц...», «Музыкант», «Газиза», «Барка», «Дикая яблоня», «Пионерская», «Красный обоз», «Красноармеец». Даны ноты песен «Голубая шаль», «Угрюм и черен лес» в записи Г. Лобачева.

## 1948

1218. Рыжкин А., төз. Татар халык көйләре. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 51 б. – 3000.

Халык җырларының ноталары һәм текстлары.

Рец.: Хәйруллина З. // Сов. әдәбияты. – 1949. – № 4. – Б. 115–117; Литинский Г. Сборник татарских народных песен // Кр. Татария. – 1949. – 8 марта.

1219. Хәйруллина З., төз. Җырлыйк, иптәшләр! – Казан: Татгосиздат, 1948. – 162 б. – 10 165.

Халык җырлары, шагыйрьләр җырлары, тәрҗемә җырлар. Текстлар тематик бүленештә китерелгән.

Рец: Хәсән Х. // Сов. әдәбияты. – 1949. – № 5. – Б. 125–126.

1220. Шамов А. һәм Ярми Х., төз. Халык җырлары. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 163 б. – 10 165.

Җыр текстлары (тематик бүленештә).

Рец.: Җәләй Л. // Сов. әдәбияты. – 1948. – № 11. – Б. 95–97; Хәйри Х. «Җырлама иске җырларны» // Кыз. Татарстан. – 1949. – 4 янв.

1221. Әхмәт А., төз. Мәкальләр. – Казан: Татгосиздат, 1948. – 24 б. – 5165.

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен җыентык.

Рец.: Фаттах Н. Җиде кат үлчә, бер тапкыр кис // Сов. әдәбияты. – 1949. – № 1. – Б. 126–127.

1222. Гали М. Пугачев хәрәкәте турында кайбер материаллар // Сов. әдәбияты. – 1948. – № 9. – Б. 98–107.

Халык иҗатында Пугачев хәрәкәтен чагылдырган материаллар турында да.

1223. Дибаева М. һәм Нуретдинова М. Халык иҗатын җыю буенча // Кыз. Татарстан. – 1948. – 27 июнь.

Бу эштә укытучыларның ярдәме кирәклеге турында.

1224. Фольклор экспедициясе // Кыз. Татарстан, – 1948. – 17 фев.

Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган фольклор экспедициясе турында.

1225. Фольклорная экспедиция // Кр. Татария. –1948. – 1 июня.

Информация об экспедиции Института языка, литературы и истории.

1226. Фольклор экспедициясе // Кыз. Татарстан. – 1948. – 8 авг.

Татар фольклорын җыю буенча республика районнарына оештырылган экспедиция йомгаклары турында.

1227. Фәйзи Җ. Халык көйләре һәм җырчылар турында // Кыз. Татарстан. – 1948. – 20 июль.

1228. Ярми Х. Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри: 1825–1945: Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. – Казан: Татгосиздат, 1948. – Б. 97–106.

1229. Ярми Х. Тукай һәм халык иҗаты // Габдулла Тукай: Шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары: 1886–1946. – Казан: Татиздат, 1948. – Б. 93–112.

1230. Три дочери. – Соловей // Головин Н. В. Сказки моей родины. – Киров: ОГИЗ, 1948. – С. 111–113, 140–143.

Татарские народные сказки (на русском языке).

1231. Шах-петух // Лесная Л. Сказки народов СССР. – Рига: Латгосиздат, 1949. – С. 86–87.

Татарская народная сказка на русском языке.

1949

1232. Әхмәт А., төз. Табышмак әйтәм – табыгыз. – Казан: Татгосиздат, 1949. – 32 б. – 5065.

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен җыентык.

1233. Мусин Исмәгыйль. Музыкаль фольклорыбыз турында // Кыз. Татарстан. – 1949. – 19 окт.

1234. Ярми Х. Бөек юлбашчы турында татар халык җырлары // Сов. әдәбияты. – 1949. – № 12. – Б. 94–100.

Мәкалә һәм текстлар.

1950

1235. Бәшир Г. Һәм Ярми Х., төз. Татар халык әкиятләре. – Казан: Татгосиздат, 1950. – 83 б. – 10 000. – Тышлыкта: 1949.

22 әкият тексты урнаштырылган.

1236. Ярми Х. XXX ел эчендә татар совет фольклоры // Сов. әдәбияты. – 1950. – № 10. – Б. 95–108.

1237. Соловей // Народные сказки. – Саратов: Обл. гос. изд., 1950. – С. 108–110.

Татарская народная сказка (на русском языке).

1237а. Три дочери. – Соловей // Сказки народов Советского Союза. – Горький, 1950. – С. 281–285.

Татарские народные сказки (на русском языке).

1951

1238. Бәширов Г., Шамов А., Ярми Х. һәм Усманов Х., төзүчеләр. Татар халык иҗаты. – Казан: Татгосиздат, 1951. – IX, 524 б. – 10 065.

СССР ФА. КФ. Тел, әдәбият һәм тарих институты. Х. Ярминең «Татар халык иҗаты» дигән кереш мәкаләсе белән. Материал «Совет чоры» һәм «Октябрьгә кадәрге чор»ларга бүленгән. Китапта татар фольклорының төп жанрлары: җырлар, бәетләр, сөйләкләр, мәкаль һәм әйтемнәр, әкиятләр урын алган. Җыр текстлары үз чиратында «Сюжетлы җырлар», «Бию җырлары» дип төрле жанрларга аерылган.

Материалларның кем тарафыннан, кайчан, кайда, кемнәрдән язып алынуы турында белешмәләр китерелгән.

Рец.: Фәттәхов Н. Татар халык иҗаты җыентыгы // Сов. әдәбияты. – 1951. – № 10. – Б. 119–125; И. Нуруллин. О сборнике «Татарское народное творчество» // Сов. Татария, 1952. – 23 фев.

1239. Өч кыз: (Әкият). – Казан: Татгосиздат, 1951. – 12 б. – 8065.

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

1240. Портной, медведь и бесенок // Булатов М. Чудесная мельница: Сказки народов СССР. – М.-Л.: Детгиз, 1951. – С. 140–145.

Татарская народная сказка (на русском языке).

## 1952

1241. Ярми Х., төз. Табышмаклар. – Казан: Татгосиздат, 1952. – 16 б. – 10 037.

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен җыентык.

1242. Баширов Г. и Ярмухаметов Х., сост. Гульчечек: Татарские народные сказки / Пер. Г. Шариповой. – М.-Л.: Детгиз, 1952. – 127 с. – 100 000.

С «Предисловием» Х. Ярмухаметова (с. 3–5). Помещено 28 сказок. Издание для учащихся нерусских школ.

Рец.: Плотникова Г. и Павлова В. Татарские сказки в русском переводе // Сов.Татария. – 1953. – 28 июля.

1243. Соловей // Народные сказки. – Саратов: Обл. гос. изд., 1952. – С. 82–84.

Татарская народная сказка (на русском языке).

1244. Только в ленинском пути счастье всех племен и рас: Татарские народные песни о В.И. Ленине // Сов.Татария. – 1952. – 21 янв.

Тексты.

1245. Basgöz I. Turkish folk stories about the lives of minstrels // Journal of American folklore. – T. 65. – 1952. – P. 551–539.

Тюркские народные легенды. Исследование и тексты.

1246. Lach Bobert and Herbert Jansky. Volksgesänge von Völkern Busslands: II. Turktatarische Völker; Kasantatarische, mischärischs, westsibirische, nogai-tatarische, turkmenische, kirgisische und tseherkessisch-tatarische Gesänge / Transkription und übersetzung

von Herbert Jansky // Sonderberichte der Wiener Akademie der Wissenschaften (Vienna). – Bd. 227. – Abt. 4. – 1952. – 227 s.

Народные песни тюркских народов России, в том числе волжских, сибирских татар, мишарей. Тексты на языке оригинала и в переводе на немецкий язык. Имеется краткое предисловие о природе, строении песен.

1953

1247. Хәйруллина З., төз. Халык җырлый (1 басма). – Казан: Татгосиздат, 1953. – 555. б. – 10 000.

Татар халык җырлары, тәрҗемә җырлар. Текстлар тематик бүленештә.

Рец.: Төхфәт Г. // Сов. әдәбияты. – 1945. – № 5. – Б. 121–125.

1248. Агай казны ничек бүлгән. – Җилән: Татар халык әкиятләре // Пионер. – 1953. – № 6. – Б. 16–17.

Ике әкият тексты, Х. Ярминең кереш сүзе белән.

1249. Бәширов Г. Халык әкиятләре // Бәширов Г. Безнең заман. – Казан: Татгосиздат, 1953. – Б. 247–262.

Татар халык әкиятләре, аларның тарихы, тематикасы, халыкның рухи тормышында тоткан урыны турында.

1250. Насыйри К. Табышмаклар. – Халык сүзләре. – Татар халык җырлары. – Әкиятләр // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татгосиздат, 1953. – Б. 205–393.

Текстлар.

1251. Фольклор экспедициясе // Сов. Татарстаны. – 1953. – 29 май.

Татарстан районнарына Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган экспедиция турында.

1252. Фольклор экспедициясе // Сов. Татарстаны. – 1953. – 9 авг.

Татарстан районнарына оештырылган экспедиция йомгаклары.

1253. Баширов Г. и Ярмухаметов Х., сост. Гульчечек: Татарские народные сказки / Пер. с татар. Г. Шариповой. – Казань: Татгосиздат, 1953. – 139 с. – 15 000.

С «Предисловием» Х. Ярмухаметова. Помещены 23 сказки. Издано для среднего школьного возраста.

1254. Песни Приволжских татар: «Белая». – «Голубая шаль». – «За конями белый след». – «...Угрюм и черен лес». – «Новое платье». – «Ключ». – «Серп как месяц». – «Газиза». –

«Дикая яблоня». – «Колыбельная». – «Пионерская». – «Красный обоз». – «Красноармеец» // Глоба А. Песни народов СССР. – Изд. 2-е, доп. – М.: Худож. лит., 1953. – С. 191–208.

Переводы на русский язык.

1255. Портной, медведь и бесенок // М. Булатов. Гора самоцветов: (Сказки народов СССР). – М.-Л.: Детгиз, 1953. – С. 215–220.

Татарская народная сказка (на русском языке).

1256. * Гөлчәчәк: (Татар халык әкиятләре). – Пекин: «Новое время», 1954. – 148 б. – 18 000.

Х. Ярми һәм Г. Бәширов төзегән татар халык әкиятләре басмасыннан кытайчага тәрҗемә ителгән 23 татар халык әкияте.

Рец.: Татар халык әкиятләре кытай телендә // Сов. Татарстаны. – 1954. – 11 ноябрь.

1257. Benzing Johannes. Lieder mit Übereinstunmenden Inhalt bei verschiedenen Völkern des Wolga-Ural Gebietes // Ural-Altaische Jahrbücher. – Bd. XXV. – 1953 (Wiesbaden). – Hf. 3/4. – S. 213–219.

О взаимовлиянии татарского, башкирского, чувашского, мордовского народов как в области текста, так и музыки, мотивов-мелодий. Примеры песен на указанных языках. О значении песни в духовной жизни народа, приведены высказывания Г. Тукая из 4-го тома его сочинений, изданных в 1930 году в Токио (Япония).

1258. Codatay S. Die Adigä-sage / Text, Übersetzung und Kommentar // Ural-Altaische Jahrbücher – Bd. XXV. – 1953 (Wiesbaden). – Hf. 3/4. – S. 243–282.

Исследование и комментарии по эпосу «Идеге». Текст в переводе на немецкий язык и на языке оригинала. История изучения эпоса в России русскими востоковедами и зарубежными ориенталистами.

1259. Paasonen Heikki. Mischärtatarische Volksdictung. Gesammelt von Heikki Paasonen / Übersetzt und herausgegefen von Eino Karahka. – Helsinki: Suamalais-Ugrilainen seura, 1953. – 163 s. – (Suamalais-Ugrilaisen seuran toimituskia Memoires de la sociéte Finno-Ougrienne. № 105).

Стр. 3–7 – вводное слово; стр. 8–120 – текст 21 татарской сказки; стр. 121–136 – текст семи баитов.

Тексты на татарском языке латинской графикой и в переводе на немецкий язык.

## 1954

1260. Баширов Г., Шамов А., Ярми Х. һәм Госман Х. Татар халык иҗаты: 2 басма. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 604 б. – 7000. СССР ФА. КФ. Тел, әдәбият һәм тарих институты.

Басмага кергән материаллар нигездә китапның 1 басмасындагы (1951) әсәрләрне эченә алган һәм төзелеше дә бер принципта.

Рец.: Халык иҗаты китабы // Сов. Татарстан. – 1954. – 13 окт.; Давлетов К. Татарское народное творчество // Сов. этнография. – 1955. – № 4. – С. 167–169; Усманов А. // Кызыл таң (Уфа). – 1955. – № 220.

1261. Насыйри К., җыючы. Әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1954. – 32 б. – 10 000.

К. Насыйри язып алган татар халык әкиятләре. Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен.

1262. Хәйруллина З., төз. Халык җырлый. – 2 басма. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 635 б. – 20 000.

Татар халык җырлары, шагыйрьләр җырлары, тәрҗемә җырлар. Текстлар тематик бүленештә.

Рец.: Садри М. Җыр китабын укыгач... // Сов. Татарстаны. – 1954. – 11 авг.

1263. Гришман Я. Татар совет җырлары турында // Сов. әдәбияты. – 1954. – Б. 82–87.

1264. Ике мулла белән бер мужик: Татар халык әкияте // Пионер. – 1954. – № 8. – Б. 29.

Текст.

1265. Ишмөхәммәтов Гаяз. Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсе материаллары // Сов. әдәбияты. – 1954. – № 11.– Б. 110–114.

Татар халык иҗаты әсәрләреннән үрнәкләр бар. «Энҗеле үрдәк» әкияте кульязмасының күчермәсе урнаштырылган.

1266. Татар халык мәкальләре // Пионер. – 1954. – № 8. – Б. 29.

Текстлар.

1267. Фольклор экспедицияләре // Сов. Татарстаны. – 1954. – 3 июнь.

Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты оештыра торган экспедицияләрнең планнары турында.

1268. Фольклор экспедицияләре // Сов. Татарстаны. – 1954. – 23 окт.

Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты экспедицияләренең йомгаклары.

1269. Ханбиков Я. Халык иҗаты әсәрләрендә татар халкының педагогик фикерләре // Сов. мәктәбе. – 1954. – № 5. – Б. 76–79.

1269а. Соловей. – Три дочери // Сказки нашей Родины. – Горький, 1954. – С. 58–61, 155–156.

Татарские народные сказки (Перевод на русский язык).

1270. Гюльчечек: Татарские народные сказки. – Ереван: Айпетрат, 1954. – 130 с.

Переводы татарских сказок на армянский язык.

1271. Соловей / Пер. З. Супрун. – Киев: «Веселка», 1954. – 14 с. – С ил. – 300 000.

Татарская народная сказка. Для детей дошкольного возраста. Перевод на украинский язык.

## 1955

1272. Ключарев А.С. , төз. Татар халык көйләре. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 248 б.

Җыр текстлары, ноталар белән.

Рец.: Надиров И. «Татар халык көйләре»нең икенче томы // Сов. әдәбияты. – 1957. – № 6. – Б. 111–117.

1273. Карәхмәт, җыючы. Хуҗа Насретдин хикмәтләре // Сов. әдәбияты. – 1955. – № 3. – Б. 124–125.

9 мәзәк тексты.

1274. Тукай Г. Халык әдәбияты. Язучыдан: (кереш сүз). – Игътизар: (халык әдәбияты турында сөйләгән лекциянең кереше һәм 6 халык көенең килеп чыгышы турында). – Халык әдәбияты: (халык җырлары турында лекциясе). – Халык моңнары: (җырлар, бәетләр). – Җырлар дәфтәрем (28 төрле җыр) // Г. Тукай әсәрләре. – Казан, 1955. – Т. 2. – Б. 255–340.

1275. Халык мәкальләре // Агитатор блокноты. – 1955. – № 15. – Б. 33.

Текстлар.

1276. Хезмәт турында мәкальләр // Агитатор блокноты. – 1955. – № 13. – Б. 54.

Текстлар.

1277. Хуҗа һәм балалар: (Мәзәк) // Пионер. – 1955. – № 9. – Б. 26.

Хуҗа Насретдин мәзәкләре циклыннан (текстлар).

1278. Шәфиев Р., җыючы. Батырлыкта – матурлык // Чаян. – 1955. – № 3. – Б. 7.

Халык мәзәге (текст).

1279. Пословицы и поговорки о труде // Блокнот агитатора. – Казань, 1955. – № 13. – С. 50.

Татарские и русские пословицы и поговорки (тексты).

1280. Ярмухаметов Х. Бережно относиться к народному творчеству // Сов. Татария. – 1955. – 29 янв.

1281. Татар табышмаклары // Пионер (Алма-Ата). – 1955. – № 5. – Б. 23.

Татарские загадки в переводе на казахский язык.

## 1956

1282. Бәширов Г. һәм Ярми Х., төз. Татар халык әкиятләре: 2 китап / СССР ФА. КФ. Тел, әдәбият һәм тарих институты. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 394 б. – 20 000.

Х. Ярминең «Татар халык әкиятләре» дигән кереш мәкаләсе белән. Әкиятләрнең кайда, кайчан һәм кем тарафынан язып алынуы турында белешмәләр бирелгән.

Рец.: Гумеров А. // Сов. Татарстаны. – 1956. – 23 сент.; «Татар халык әкиятләре» // Сов. әдәбияты. – 1956. – № 12. – Б. 111–112.

1283. Тапкыр егет: Татар халык әкиятләре. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 71 б. – 15 000.

Әкиятләр җыентыгы. Мәктәп балалары өчен.

1284. Татар поэзиясе антологиясе. – Казан: Таткнигоиздат, 1956.

23–40 битләрдә революциягә кадәрге «Җырлар», «Бәетләр», 311–325 битләрдә революциядән соң туган җырлар, уен җырлары, бәетләр текстлары китерелгән.

1285. Насыйри К. Табышмаклар // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – 2 басма. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б. 203–204.

26 татар халык табышмагы һәм аның җаваплары бирелгән.

1286. Насыйри К. Татар халык җырлары // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – 2 басма. – Таткнигоиздат, 1956. – Б. 210–221.

43 җыр тексты китерелгән.

1287. Насыйри К. Халык сүзләре // Сайланма әсәрләр. – 2 басма. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б. 205–209.

170 халык мәкале бирелгән.

1288. Насыйри К. Әкиятләр // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – 2 басма. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б. 222–246.

«Байдек», «Үги кыз», «Өч угыл», «Гөлнәзек», «Саламторхан», «Төлке», «Аю белән Төлке», «Мәче белән Аю» әкиятләренең текстлары.

1289. Хисмәтуллин Ф. Татар халык җырларында Ленин образы // Сов. Татарстаны. – 1956. – 22 сент.

1290. Бәширов Г. и Ярмухаметов Х., сост. Гульчечек: Татарские народные сказки / Пер. с татар. Г. Шариповой. – Казань: Таткнигоиздат, 1956. – 140 с. – 5000.

С «Предисловием» Х. Ярмухаметова, стр. 3–4. Помещены 23 сказки в русском переводе. Издано для среднего школьного возраста.

1291. Золотой перстень: Татарские народные сказки / Сост. Х. М. Мухтаров. – Казань: Таткнигоиздат, 1956. – 68 с.

Тексты (на русском языке).

1292. Пословицы о бережливости и трудолюбии // Блокнот агитатора. – Казань, 1956. – № 1. – С. 35–36.

Татарские и русские пословицы (тексты).

1293. Соловей: Татарская народная сказка: Для дошкольного возраста / Пер. З. Супрун. – Киев: «Модоль», 1956. – 12 с. – С ил. – Сказки моей родины. – 215 000.

Перевод на украинский язык.

1957

1294. Күңелле сәхнә: Үзешчән сәнгать коллективлары өчен җыентык: 9 китап. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 195 б.

Басманың «Конферансье өчен» дигән бүлегендә татар халык мәзәкләре китерелә.

1295. Фәйзи Җ., төз. Татар халык җырлары. – Казан: Татгосиздат, 1957. – 182 б.

Җыр текстлары, ноталар белән.

1296. Хәйруллина З., төз. Революцион җырлар. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 35 б.

Татарча һәм тәрҗемә җырлар, шагыйрьләрнең музыкага салынган җырлары (текстлар).

1297. Җәләй Л., Борһанова Н. һәм Мәхмүтова Л., төз. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 144 б.

«Төзүчеләрдән» дигән кереш сүз белән. Материаллар «Мәгънәдәш фразеологик берәмлекләр» һәм «Аерым сүзләр мәгънәсеннән ясалган фразеологик бермәлекләр» дигән ике бүлектә бирелгән, кулланылган чыганаклар күрсәтелгән.

1298. Абдуллин З. һәм Надиров И. Татар халыкның музыкальпоэтик иҗаты турында // Сов. Татарстаны. – 1957. – 19 июнь.

1299. Икмәгем юк: Халык юморы // Ялкын. – 1967. – № 10. – Б. 7.

Мәзәк тексты.

1300. Надиров И. Бөек Ватан сугышы елларында халык җырлары // Сов. әдәбияты. – 1957. – № 3. – Б. 92–100.

1301. Надиров И. һәм Гатина Х. Татар халык мәкальләрен җыю эше // Сов. Татарстаны. – 1957. – 21 апр.

1301а. Надиров И., Гатина Х. Зур галим // Сов. Татарстаны. – 1957. – 29 дек.

Тел, фольклор галиме Хуҗа Бәдигыйгә 70 яшь тулу уңае белән.

1302. Халык җырлары // Мирхәйдәр Фәйзи. Сайланма әсәрләр: 2 томда. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – Т. 1. – Б. 171–242.

Мирхәйдәр Фәйзи тарафыннан тупланган татар халык җырлары текстлары. Җыючының кереш сүзе белән. Җырлар тематик бүленештә бирелгән.

1303. Ярми Х. 40 ел эчендә татар совет фольклористикасы // Сов. әдәбияты. – 1957. – № 11. – Б. 138–144.

1304. Ярми Х. Татар фольклористика фәненең күренекле галиме // Сов. әдәбияты. – 1957. – № 12. – Б. 62–64.

Хуҗа Бәдигый турында.

1305. Антология татарской поэзии. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 606 с. – 8000.

Представлены произведения татарского фольклора: дореволюционные и послереволюционные песни, баиты.

1306. Ярмухаметов Х., сост. Татарские народные сказки. – М.: Детгиз, 1957. – 318 с. – 100 000.

Тексты 33 сказок в переводе на русский язык.

Рец.: Павлова В. // Сов. Татария. – 1958. – 16 апр.; Касыймов Э. Татар халык экиятләре рус телендә // Совет әдәбияты. – 1958. – № 3. – Б. 110–115.

1307. Ярмухаметов Х., сост. Татарские народные сказки: Пер. с татарского языка. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 214 с.; 6 л. ил. – 75 000.

Тексты 34 татарских сказок.

Рец.: Павлова В. Хорошая книга для маленьких читателей // Комсомолец Татарии. – 1958. – 2 апр.

1308. Махмутова Л. Т. Старинная свадебная песня у касимовских татар // Изв. Казанского филиала АН СССР: Серия гум. наук. – 1957. – Вып. 2. – С. 217–221.

Исследование и тексты.

1309. Портной, медведь и бесенок // Булатов М. Гора самоцветов: Сказки народов СССР. – М.: Детгиз, 1957. – С. 228–234.

Татарская народная сказка (на русском языке).

1310. Татарские пословицы // Огонек. – 1957. – № 21. – С. 32.

Тексты (на русском языке).

1311. Шах-Петух. Татарская народная сказка: (Для дошкольного и младш. школьного возраста) / Пересказал в стихах И. Нехода; пер. с украинского А. Прокофьев. – Л.: Детгиз, 1957. – 12 с. – С ил. – 100 000.

Текст (на русском языке).

1311а. Шах-Петух: Татарская народная сказка / Пересказал в стихах И. Нехода. Пер. с укр. А. Прокофьев. – Ташкент, 1957. – 12 с. – 30 000.

1312. Ярмухаметов Х. Х. и Павлова В. Ф. Некоторые итоги фольклорных экспедиций: (1955–1956) // Изв. Казанского филиала АН СССР. Серия гум. наук. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – Вып. 2. – С. 209–213.

1313. Ярмухаметов Х. Татарская советская фольклористика за 40 лет // Известия Казанского филиала АН СССР. Юбилейный сборник. – Казань, 1957. – С. 173–181.

1314. Гульчечек: Татарские народные сказки: Для детей / Сост.: Г. Баширов, Х. Ярмухаметов; вступ. статья Х. Ярмухаметова; пер. с рус. К. Камбаров. – Алма-Ата: Казгослитиздат, 1957. – 127 с.; с ил. – 10 000.

Татарские сказки на казахском языке.

## 1958

1315. Бәширов Р. һәм Ярми Х. Татар халык әкиятләре: 1 китап / СССР ФА. КФ. Тел, әдәбият һәм тарих институты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – XXV. – 359 б. – 10 000.

Х. Ярминең кереш мәкаләсе белән. Җыентыкка кергән әкиятләрнең кайда, кемнән, кайчан, кем тарафыннан язылып алынуы турында белешмәләр китерелгән.

1316. Гыйззәтуллин Нур. Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 230 б. – 5000.

Татар фольклоры жанрлары терминологиясенә дә аңлатмалар бирелә.

1317. Хәйруллина З., төз. Халык җырлый. – 3 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – 667 б. – 15 000.

Татар халык җырлары, шагыйрьләр җырлары, тәрҗемә җырлар. Текстлар тематик бүленештә урнаштырылган.

Рец.: Надиров И. «Халык җырлый» җыентыгының өченче басмасы // Сов. әдәбияты. – 1958. – № 8. – Б. 116–124.

1318. Бәширов Г., җыючы. Татар халык мәзәкләре // Ялкын. – 1958. – № 2. – Б. 27.

4 мәзәк тексты.

1319. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләренең шигъри үлчәмлеге // Сов. әдәбияты. – 1958. – № 5. – Б. 97–109.

Мәкалә. Фикер алышу тәртибендә басыла.

1320. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләренең шигъри бер үзенчәлеге – рифмалары турында // Сов. әдәбияты. – 1958. – № 11. – Б. 96–99.

Шушы ук журналның 1958 елгы 5 нче санында басылган мәкаләнең дәвамы булып тора.

1321. Надиров И. Көнчыгыш әкиятләре татар телендә // Сов. әдәбияты, 1958. – № 9. – Б. 124–126.

Революциягә хәтле һәм аннан соңгы тәрҗемәләр турында.

1322. Надиров И. Совет Армиясе турында татар халык җырлары // Сов. әдәбияты. –1958. – № 3. – Б. 107.

Мәкалә.

1323. Надиров И. Солдат җырлары // Сов. Татарстаны. – 1958. – 26 фев.

Мәкалә.

1324. Надиров И. Халык иҗатын җыйнау // Сов. Татарстаны. – 1958. – 17 июль.

1325. Садыйкова Р., язып алучы. Тау җыры: Халык иҗаты // Азат хатын. – 1958. – № 12. – Б. 21.

Җыр тексты.

1326. Совет Армиясенә дан: Татар халык җырларыннан // Азат хатын. – 1958. – № 2. – Тышлыкта.

Текстлар.

1327. Татар халык мәзәкләре // Ялкын. – 1958. – № 3. – Б. 33.

Өч мәзәк тексты.

1328. Татар халык мәзәкләре // Ялкын. – 1958. – № 8. – Б. 31.

Өч мәзәк тексты.

1329. Шушами әкияте: Румыния татарлары әкияте // Ялкын. – 1958 – № 1. – Б. 27–28.

Текст.

1330. Ярми Х., язып алучы. Ике ялганчы: Татар халык әкияте // Ялкын. – 1958. – № 9. – Б. 19–20.

Текст.

1331. Әхмәт солдат, җыючы. Хуҗа Насретдин мәзәкләре // Ялкын. – 1958. – № 3. – Б. 6–7.

Текстлар. Әхмәт солдат – язучы Абдулла Әхмәтнең псевдонимы.

1332. Вопросы изучения эпоса народов СССР. – М.: Изд-во АН СССР, 1958. – 291 с.

В статьях В.М. Жирмунского «Некоторые итоги изучения героического эпоса Средней Азии» (стр. 24–65), А.К. Боровкова «Вопросы изучения тюркоязычного эпоса народов Средней Азии и Казахстана» (стр. 66–100), Л.И. Климовича «Заметки об эпическом творчестве народов Среднего Востока» (стр. 239–290) рассматриваются и памятники татарского эпоса, татарские варианты «Алпамыш», Куз-Курпяче», «Кероглы» и др.

1333. Портной, медведь и бесенок: Татарская сказка // Гора самоцветов: Сказки народов СССР / Пересказал М. Булатов. – Ташкент, Госучпедизд Уз. ССР, 1958. – С. 219–224.

Текст сказки на русском языке.

## 1959

1334. Исәнбәт Н., җыючы, төзүче. Татар халык мәкальләре: 3 томда. – Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 916 б. – 10 000.

Төзүченең зур күләмле кереш мәкаләсе белән. Китапта мәкальләр тематика буенча системалаштырылган. Мәкальләрнең кайдан яки

кайсы чыганаклардан язып алынуы, аерым очракларда башка телләрдәге вариантлары, эквивалентлары күрсәтелә. Бу хезмәтнең өч томында да шулай эшләнгән.

Рец.: Алмаз Җ. Туган тел хәзинәсе // Сов. әдәбияты, 1960. – № 9. – Б. 134–149; Җәләй Л. Туган тел байлыгы // Социалистик Татарстан. – 1960. – 3 фев.; Рафиков М. Книга народной мудрости // Литература и жизнь. – 1961. – 15 фев.

1335. Рәхмәт Б. Табышмаклар һәм башваткычлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 16 б. – 17 000.

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен халык табышмаклары һәм автор иҗат иткән әсәрләр.

1336. Хәйруллина З., төз. Халык җырлый. – 4 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 660 б. –25 000.

Татар халык җырлары һәм шагыйрьләр җырлары. Текстлар тематик бүленештә урнаштырылган.

1337. Өч кыз: Татар халык әкияте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 11 б. – 19 000.

Мәктәп балалары өчен чыгарылган басма.

1338. Абдуллин Ә. Татар халык музыкаль иҗатының үсү юлы // Татарстан яшьләре. – 1959. – 12 март.

1339. Бакиров Әнвәр. Музыкаль фольклор турында // Сов. Татарстаны. – 1959. – 12 апр.

1340. Бәширов Г. Мәзәк турында бер-ике сүз // Сов. әдәбияты. – 1959. – № 9. – Б. 108–118.

20 мәзәк тексты белән.

1341. Бүгенге җырлар турында сөйләшү // Сов. әдәбияты. – 1959. – № 12. – Б. 120–121.

1342. Гадилек һәм намуслык турында // Ялкын. – 1959. – № 3. – Б. 31.

Мәзәкләр (текстлар).

1343. Гатина Х. Нократ һәм Глазов татарларының җырлары турында // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 1 чыгарылыш. – Б. 318–323.

1344. Гафурова Гөлчирә, җыючы. Балалар сөйләше // Азат хатын. – 1955. – № 11. – Б. 19.

Текстлар.

1345. Ибраһимов С. Халык иҗатында дингә каршы карашларның чагылышы // Ильич васыятьләре. – 1959. – 6 март.

1346. Илаһи бәет. Тукаев үлү мөнәсәбәте илә // Тукай турында замандашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – Б. 215–217.

Аннотациясе бәетнең 1913 елда чыккан басмасында.

1347. Исәнбәт Н., җыючы. Мин музыкант. – Салчылар. – Иң матур сүз. – Айсылу кайда? //Ялкын. – 1959. – № 8. – Б. 8–9.

Балалар уеннары. Аңлатма белән.

1348. Исәнбәт, җыючы. Татар халык мәзәкләре // Чаян. – 1968. – № 8. – Б. 7; № 12. – Б. 7.

Текстлар.

1350. Комсомолка Нәфисә // Татарстан яшьләре. – 1959. – 14 июль.

Татар халык җыры (текст).

1351. Мозаффаров Рәфикъ. Халык әдип ул, шагыйрь ул... // Азат хатын. – 1959. – № 9. – Б. 15.

Мәкалә (халык иҗаты турында).

1352. Надиров И. Бөек Ватан сугышы чорында халык иҗаты // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 1 чыгарылыш. – Б. 214–249.

1353. Надиров И. Бөек Ватан сугышы чорында татар халык мәкальләре // Татар теле һәм әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 1 чыгарылыш. – Б. 250–261.

1354. Надиров И. Татар халык җыр иҗатында Ленин образы // Татарстан коммунисты. – 1959. – № 4. – Б. 40–43.

1355. Партиябез сызган юлдан җиңеп алга барабыз: Татар халык җырлары // Ялкын. – 1959. – № 1. – Б. 1.

Текстлар.

1356. Саттаров Г., язып алучы. Гөлшикәр: Татар халык әкияте // Азат хатын. – 1959. – № 9. – Б.16–17.

Текст.

1357. Саттаров Г. Себер татарларының җырлары // Азат хатын. – 1959. – № 10. – Б. 12–13.

Текстлар белән.

1358. Халык җырлый // Сов. әдәбияты. – 1959. – № 3. – Б. 91–104.

Пенза өлкәсендә И. Надиров, Р. Кәримов, Х. Ярми, Х. Гатина язып алган җырлар. Шул ук өлкәдә Э. Касыймов язып алган «Әй, казак камчысы» бәете һәм ул бәет турында. Тоболь өлкәсендә Г. Саттаров язып

алган Тобол татарларының җырлары һәм «Миңнулла» бәете (аңлатмалар белән). Ширәмәт районында Х. Курбатов язып алган «Салих бәете». Әгерҗе һәм Яңавыл (БАССР) районында И. Юзеев, Х. Гатина, И. Надиров язып алган җырлар. Норлат районы һәм Кама Тамагы районында И. Надиров язып алган җырлар.

1359. Халык мәзәкләре // Чаян. – 1959. – № 24. – Б. 6–7.

Текстлар.

1360. Музафаров Р. И. Татарские народные пословицы: О пословицах крымских татар. – Казань: Изд-во ун-та, 1959. – 43 с. – 1000.

Исследование. Есть сравнения с пословицами казанских татар.

1361. Надиров И. Н. Татарское народно-поэтическое творчество периода Великой Отечественной войны: Автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань; 1959. – 19 с. – 150.

1362. Надиров И. Образ Ленина в песенном творчестве // Коммунист Татарии, 1959. – № 4. – С. 40–42.

1363. Находчивый джигит. – Гульчечек. – Саран и Юмарт. – Татарские народные сказки // Сказки народов СССР. – Астрахань: Изд. газеты «Волга», 1959. – С. 163–181.

Тексты на русском языке.

1364. Татарская песня о Ленине / Пер. В. Ганиев // Сов. Татария. – 1959. – 15 апр.

## 1960

1365. Бикмөхәммәт Р. Поэзиябезнең сулмас чәчәкләре: Традицион образларны өйрәнү тәҗрибәсеннән. – Казан: Таткнигоиздат, 1960. – 208 б. – 3000.

127–142 битләрдә татар әдәбиятының халык иҗаты белән бәйләнеше турында языла.

1366. Бәширов Г., төз., әдәби эшкәртүче. Туксан тугыз мәзәк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 88 б. – 15 000.

Мәзәкләр җыентыгы. Төзүченең мәзәкләр турында кереш сүзе белән.

Рец.: Абдулла Ә. // Сов. Татарстаны. – 1960. – 30 окт.

1367. Козлова Р. һәм Хуҗиханова Г., төз. Нәниләр китабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 450 б. – 6000.

Матур әдәбият әсәрләре белән бергә әкият, мәзәк, табышмак текстлары да бирелгән.

1368. Колхозың алда булса, авызың балда булыр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 112 б. – 10 000.

Үзешчән сәнгать һәм агитаторлар өчен чыгарылган бу басмада «Халык җырлары» (74–84 бб.) һәм «Татар халык мәкальләре» (84–89 бб.) дә урнаштырылган. Текстларны җыентык өчен Х. Гатина һәм Х. Ярми тапшырган.

1369. Насыйри К., җыючы. Әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 31 б. – 11 000.

К. Насыйри язып алган әкиятләрдән 7 текст. Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен чыгарылган басма.

1370. Нәниләр китабы: (Хикәяләр, шигырьләр, әкиятләр, мәзәкләр, табышмаклар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

Басманың 64–65, 69–72, 174–175, 182–186, 395–399, 408, 410–411, 418–422 битләрендә татар халык әкиятләре, җырлары, мәзәкләре, тапкыр сүзләр, көлдергечләр, табышмаклар, санамышлар китерелгән.

1371. Шомбай: Татар халык әкиятләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 195 б. – 11 000.

Г. Бәширов, Х. Ярми төзегән әкият җыентыкларыннан сайлап алып, олы яшьтәге балалар өчен хәзерләнгән басма.

1372. Ярми Х., төз. Бәетләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 388 б. – 12 000.

СССР ФА. КФ. Тел, әдәбият һәм тарих институты.

Төзүченең «Сүз башы» белән. Китапта бәетләр, «Борынгы чордан XIX йөз урталарына кадәр», «XIX йөзнең урталарыннан Октябрь революциясенә кадәр», «Совет чоры» дип, өч периодка бүлеп бирелгән. Бәетләр турында кыскача белешмәләр, кайда, кемнән, кайчан язып алынулары кебек мәгълүматлар китерелгән.

Рец.: Максютова Р. «Бәетләр» җыентыгы турында // Кызыл Таң (Уфа). – 1961. – 16 апр.

1373. Ярми Х., төз. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 243 б. – 9000.

Төзүченең «Мәкальләр һәм әйтемнәр турында» дигән кереш мәкаләсе белән. Текстлар тематик бүленештә урнаштырылган. Әдәбият исемлеге китерелгән.

Рец.: Ахунҗанов Г. Мәкальләр һәм әйтемнәр турында // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 12. – Б. 123–125.

1374. Кәҗә бәтиләре һәм бүре: Татар халык әкияте. – Халык җырлары, мәзәкләр, тапкыр сүзләр, көлдергечләр. – Ата каз. – Гөлчәчәк. – Аю белән бабай. – Шүрәле. – Көрәшче белән аю. – Төлке белән бүре. – Аю белән Кояш. – Кем көчле: Татар халык әкиятләре. – Халык җырлары, мәзәкләр, тапкыр сүзләр, көлдергечләр, санамышлар, табышмаклар. – Көйсез бала: Татар халык әкияте // Нәниләр китабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – Б. 64–65, 69–72, 174–175, 182–186, 395–399, 408, 410–411, 418–420.

Текстлар.

1375. Илаһи бәет: Тукаев үлү мөнәсәбәтилә // Тукай турында замандашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – Б. 215–217.

Бәетнең тексты, чыгарылуы турында аңлатма. Аңлатма авторы һәм бәетне язып алучы – «Ч».

1376. Абдуллин Ә. Татар халык музыкасының үзенчәлекләре // Соц. Татарстан. – 1960. – 23 ноябрь.

1377. Бакиров Әнвәр. Көйләр җыючы // Сов. Татарстаны. – 1960. – 23 март.

Халык көйләре һәм җыр текстлары туплаучы һәвәскәр Г. Гобәйдуллин турында.

1378. Бәширов Г. Ягез әле, иптәшләр... // Татарстан яшьләре. – 1960. – 17 март.

Халык мәзәкләре, кыска әкиятләрне җыю турында.

1379. Бикулов Х., җыючы. Хуҗа мәзәкләре // Азат хатын. – 1960. – № 11 – Б. 24.

Текстлар.

1380. Гобәйдуллин Г., язып алучы. Яшьлек җыры: Халык көе // Татарстан яшьләре. – 1960. –22 март.

Текст (нота белән).

1381. Гыйззәтуллин Наил, язып алучы. Яр, яр: Хәзерге заман туй җыры // Татарстан яшьләре. – 1960. – 22 март.

Текст.

1382. Гыйззәтуллин Н. Тутыкмас вә күгәрмәс көзгедер // Татарстан яшьләре. – 1960. – 29 март.

Татар халык иҗаты турында.

1383. Касыймов Э., язып алучы. Мактанчык бай: Әкият // Сов. Татарстаны. – 1960. – 23 март.

1384. Касыймов Э., язып алучы. Мулла эләкте // Азат хатын. – 1960. – № 1. – Б. 14–15.

Әкият тексты.

1385. Касыймов Э., язып алучы. Үрдәкнең ите күбрәк. – Ярлы белән бай // Татарстан яшьләре. – 1960. – 22 март.

Мәзәкләр (текстлар).

1386. Кротов А., тапшыручы. Алтын кармак: Халык җыры // Сов. Татарстаны. – 1960. – 23 март.

Текст.

1387. Ленин бабай васыять әйткән: укырга һәм укырга: татар халык җырлары // Ялкын. – 1960. – № 4. – Б. 25.

Текстлар.

1388. Надиров И. Бер шигырьнең язмышы // Сов. әдәбияты. – 1960. – № 8. – Б. 154–155.

Халык җырына әйләнгән әсәр турында.

1389. Надиров И. Сугыш чоры бәетләре // Азат хатын. – 1960. – № 9. – Б. 22–23.

Мәкалә.

1390. Надиров И., язып алучы. Туган җирем: Борынгы җыр // Татарстан яшьләре. – 1960. – 22 март.

Текст.

1391. Надиров И. Халыклашкан җырлар тарихыннан // Сов. әдәбияты. – 1960. – № 2. – Б. 88–95.

1392. Надиров И. Җыр – яшьлекнең канаты // Татарстан яшьләре. – 1960. – 22 март.

Татар халык җырлары турында.

1393. Татар халык иҗатына багышланган кичә // Сов. әдәбияты. – 1960. – № 2. – Б. 127.

Башкорт дәүләт университетында үткәрелгән кичә турында.

1394. Усманова Р., тапшыручы. Сагынам туган илемне: Җыр // Сов. Татарстаны. – 1960. – 23 март.

Текст.

1395. Халык иҗаты кичәсе // Сов. әдәбияты. – 1960. – № 5. – Б. 157.

1396. Хәсәнов Х. Шәкерт җырлары // Сов. әдәбияты. – 1960. – № 11. – Б. 152–153.

Ике җыр үрнәге белән (1905–1907 елларда иҗат ителгәннәр).

1397. Ярми Х. Татар совет халык авыз иҗаты // Татар совет әдәбияты тарихы: Очерклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – Б. 773–821.

Совет чоры татар фольклоры, традицион жанрларның үсеше, татар әдәбиятының фольклор белән бәйләнеше турында.

1398. Ярми Х. Тутыкмас көзге // Сов. Татарстаны. – 1960. – 23 март.

Татар халык иҗаты турында.

1399. Ярми Х. Халык авыз иҗатында бөек Ленин образы // Сов. әдәбияты. – 1960. – № 4. – Б. 45–52.

1400. Әхмәров З., җыючы. Татар халык мәзәкләре // Яшь кын. – 1960. – № 9. – Б. 31.

4 мәзәк тексты.

1401. Җырлар. – Мәкальләр // Сов. Татарстаны. – 1960. – 23 март.

Текстлар.

1402. Жирмунский В. М. Сказание об Алпамыше и богатырская сказка. – М.: Изд-во вост. лит., 1960. – 335 с.

На стр. 85–113 рассматривается «Кипчакская версия (башкирские, татарские, казахские сказки)» об Алпамыше.

1403. Гульчечек: Татарские народные сказки / Пер. с рус. – Киев: Детгиз, 1960. – 113 с.; с ил. – 47 000.

Тексты. Перевод на украинский язык.

1404. Quelquejav Ch. Les versions kirghize et tertare de Kazan de la légende des Sept Dormants // Revue des études islamiques (Paris). – T. 28. – 1960. – P. 115–119.

О сходстве отдельных легенд у татар и киргизов.

## 1961

1405. Зәйнашева Г. һәм Гыйләҗев А., төз. Шиңгән әрекмәннәр: Дингә каршы әсәрләр җыентыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр.., 1961. – 131 б. – 6000.

Язучыларның дингә каршы әсәрләре белән бергә татар халкының атеистик рухтагы мәзәкләре һәм мәкальләре дә китерелгән.

1406. Касыймов Э. Татар халык иҗатында атеистик мотивлар. – Казан, 1961. – 23 б. – 750. Политик һәм фәнни белемнәр тарату буенча РСФСР җәмгыятенең Татарстан бүлеге.

1407. Кәримуллин Ә. Татар халык иҗаты. – Н.И. Лобачевский исем. фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. – Казан, 1961. – 35 б. –VI чыгарылыш. – 500.

Китапханәдә кулъязма хәлендә саклanучы татар әкиятләре, җырлары, мәкаль-әйтемнәре, бәетләре һ.б. тасвирламасы.

1408. Надиров И. Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты. – СССР ФА. КФ. Тел, әдәбият һәм тарих институты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. – 192 б. – 3000.

Эчтәлеге: I. Фронт фольклоры: Фронт җырлары. – Фронт бәетләре. II. Тыл фольклоры: Җырлар. – Бәетләр. III. Буйсынмас кешеләр иҗаты. IV. Кушымта. Биредә җырлар, бәетләрнең текстлары урнаштырылган. Аларның кайда, кайчан һәм кемнән, кем тарафыннан язылып алынуы турында белешмәләр китерелгән.

Рец.: Беляев Г. Беренче адым // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 3. – Б. 153–155.

1409. Безгә сугыш кирәкми // Соц. Татарстан. – 1961. – 9 май.

Бәет тексты.

1410. Бәширов Г. Күңел байлыгы // Сов. мәктәбе. – 1961. – № 7. – Б. 41.

Мәзәкләр турында.

1411. Касыймов Э. Татар халык иҗатында атеистик мотивлар // Соц. Татарстан. –1961. – 1 июль.

1412. Кудаш Афзал. Габдулла Тукай һәм башкорт халык иҗаты // Сов. әдәбияты. – 1961. – № 4. – Б. 63–65.

1413. Мәкальләр, әйтемнәр // Соц. Татарстан. – 1961. – 1 июль. Текстлар.

1414. Пехтелев И. Габдулла Тукайның халык иҗаты турындагы фикерләре // Сов. әдәбияты. – 1961. – № 4. – Б. 56–58.

1415. Такмаклар // Соц. Татарстан. – 1961. – 1 июнь.

Текстлар.

1416. Туган-үскән ил өчен: Халык җырлары // Ялкын. – 1961.

Текстлар.

1417. Хезмәт-һөнәр турында мәкальләр // Сов. мәктәбе. – 1961. – № 3. – Б. 37.

Текстлар.

1418. Хуҗа Насретдин мәзәкләре. – Мәкальләр // Шиңгән әрекмәннәр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. – Б. 115–129.

19 мәзәк һәм күп кенә дингә каршы мәкальләр китерелгән.

1419. Ярми Х. Бер бәетнең тарихы // Соц. Татарстан. – 1961. – 1 июль.

«Шәрәф мулла», «Ярлы белән мулла» дигән бәетләрнең текстлары белән.

1420. Ярми Х. һәм Гатина Х. Бездна вакыйгасына 100 ел // Сов. әдәбияты. – 1961. – № 4. – Б. 152–154.

1861 елгы крестьяннар күтәрелеше турында (сөйләкләр текстлары белән).

1421. Ярми Х., Надиров И., Гатина Х. һәм Кәримов Р., язып алучылар. Яңа җырлар, яңа мәзәкләр // Сов. әдәбияты. – 1961. –№ 3. – Б. 128–131.

Текстлар (Оренбург өлкәсендә язып алынганнар).

1422. Татарские пословицы и поговорки (Собрала и перевела Валитова А.А.) // Пословицы и поговорки народов Востока. – М.: Изд-во вост. лит., 1961. – С. 475–496.

Приведены в переводе на русский язык 745 татарских пословиц и поговорок. Расположены по алфавиту.

1423. Надиров И. О современной татарской поэзии // О современном народном поэтическом творчестве республик Поволжья. – М., 1961. – С. 11–28.

1424. Татарские сказки / Пер. с татарского Г. Есбатыров. – Алма-Ата, 1961. – 206 с.; с ил. – 11 000.

Тексты на казахском языке.

1425. Гульчечек: Татарские народные сказки / Предисловие Х. Ярмухаметова; пер. с рус. А. Караев. – Ашхабад: Туркменгосиздат; 1961. – 141 с.; с ил. – 7000.

Тексты на туркменском языке.

1426. Jansen W.H. Turkish folklore: an introduction // Journal of the American Folklore. – T. 74. –1961. – P. 354–561.

Введение в народно-поэтическое творчество тюркских народов.

## 1962

1427. Касыймов Э., төз. Абага чәчәге: Татар халкының сатирик әкиятләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 196 б. – 15 000.

Текстлар. Төзүченең «Сатирик әкиятләребез турында» дигән кереш сүзе белән.

1428. Касыймов Э., төз. Тапкыр кыз. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 32 б. – 20 000.

8 татар әкияте тексты. Мәктәп балалары өчен чыгарылган басма.

1429. Хәйруллина З., төз. Халык җырлый. – 5 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 536 б. – 75 000.

Текстлар. Халык җырлары, шагыйрьләр җырлары, тәрҗемә җырлар.

1430. Әхмәт А., җыючы, әдәби эшкәртүче. Хуҗа Насретдин мәзәкләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 232 б. – 30 000.

Х. Ярминең «Хуҗа Насретдин мәзәкләре», төзүченең «Төзүчедән бер-ике сүз» дигән мәкаләләре белән. Мәзәкләр тематик бүленештә урнаштырылган.

Рец.: Надиров И. // Сов. әдәбияты. – 1963. – № 3. – Б. 147–149.

1431. Бәширов Г., җыючы. Мәзәкләр // Азат хатын. – 1962. – № 3. – Б. 23.

7 мәзәк тексты.

1432. Бәширов Г., җыючы. Татар халык мәзәкләре // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 9. – Б. 148–152.

23 мәзәк тексты.

1433. Бәширов Г., җыючы. Халык мәзәкләре // Азат хатын. – 1962. – № 11. – Б. 23.

6 мәзәк тексты.

1434. Дуслык турында татар халык мәкальләре // Ялкын. – 1962. – № 11. – Б. 24.

Текстлар.

1435. Надиров И. Рус-француз сугышы бәете // Соц. Татарстан. – 1962. – 18 окт.

1812 елгы Ватан сугышының татар фольклорында чагылышы турында.

1436. Поздеев П. Удмурт фольклорын беренче җыючы – татар укымышлысы // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 12. – Б. 134.

Б.В. Гаврилов эшчәнлеге турында.

1437. Татар халык иҗаты кичәсе // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 4. – Б. 158–159.

Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм татар сәнгате театр көчләре белән оештырылган кичә турында мәгълүмат.

1438. Усманов Миркасыйм, җыючы. Бараба татарлары фольклоры // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 6. – Б. 140–144.

Җыр текстлары белән.

1439. Фольклор экспедициясе // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 9. – Б. 159.

Казан университеты татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентларының Уралга экспедициясе турында.

1440. Халык тапкыр ул // Соц. Татарстан. – 1962. – 27 март.

Татар халык иҗаты турында (фольклор текстлары белән).

1441. Шакиров Г., җыючы. Тавык-батыр. – Чиста карга. – Аксак торна // Соц. Татарстан. – 1962. – 30 сент.

Мәзәк (текстлары).

1442. Ярми Х. Гомәр Бәширов әсәрләрендә халык поэзиясе // Сов. әдәбияты. – 1962. – № 9. – Б. 117–126.

1443. Ярми Х. Исеме халык телендә // Соц. Татарстан. – 1962. – 21 дек.

Татар халык иҗатында Ленин образы.

1444. Яңа табышмаклар // Азат хатын. – 1962. – № 4. – Б. 24; № 6. – Б. 24; № 8. – Б. 24.

Текстлар.

1445. Жирмунский В. Народный героический эпос: Сравнительно-исторический очерк. – М.-Л.: Изд-во худож. лит., 1962. – 435 с.

